ҖӘЙ ХАКЫ

«ВТ» хәбәрчесе кызу айлардагы чыгымнарны исәпләде

> 5

КУЫШ КИРӘК

Студентларга кайда яшәү отышлырак?

> 7

ХӘЛИТКЕЧ БӘРЕЛЕШ

Курск сугышында катнашкан 103 яшьлек Зиннәтулла Заһидуллин хатирәләре

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 95 (29062) | Җомга | 7 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131



vk.com

ХУШ, КОВИД!

ЧИР КИТТЕ, НИНДИ ГАДӘТЕ КАЛДЫ?

Барыбыз өчен дә көтелмәгән сынау булган, ныклыгыбызны сынаган, күкрәк тутырып сулыш алуның, сәламәтлекнең кадерен белергә өйрәткән мәкерле вирус, ниһаять, биреште. Яз азагында коронавирус пандемиясе бетте дип игълан ителде. Әле бу көннәрдә генә тормышыбыздан «ПЦР-тест» дигән төшенчә дә юкка чыкты. Коронавирус безне нәрсәгә өйрәтте? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанда Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил, Төбәкне идарә итү үзәге проект офисы рәисе Сәрия Сабурская әйтүенчә, республикада яшәүчеләр бездәге экологик вазгыятьне уртача 3,11 балл (максималь балл – 5) дәрәҗәсендә бәяли. Шәһәрдә яшәүчеләр – 2,97, авыл халкы – 3,32 балл дәрәҗәсендә.

Шәһәрдә яшәүчеләр фикеренчә, экологиягә сәнәгать предприятиеләре һәм башка чыганаклар тискәре йогынты ясый. Быел Дәүләт хезмәтләре порталы аша экология мәсьәләләре буенча – 110, «Халык контроле» системасы аша 771 шикаять кергән.

Ел башыннан бирле «Инцидент менеджмент» күзәтү системасы (социаль челтәрләрдә кешеләрнең шикаятьләрен автомат рәвештә күзәтеп бару программасы) экология һәм калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча 1,8 меңнән артыграк мөрәҗәгатьне теркәгән. «Халык контроле» системасында да бу мәсьәләләр иң еш кабул ителгән мөрәҗәгатьләр унлыгына керә.

Бүгенгә Татарстанда 56 комлыкның 53е эшли. Шул исәптән 41е – муниципаль, 2се – шифаханә, 6сы – ял базасы, 1се – студентлар лагере, 3есе – балалар лагере комлыклары. Тагын 2 муниципаль пляж озакламый ачылачак.

Сүз уңаеннан, ел башыннан бирле республика сулыкларында 27 кеше, шул исәптән 2 бала һәлак булган. 41 кешене коткарып өлгергәннәр. Шул ук вакытта коену сезоны ачылганнан бирле (1 июнь) елга-күлләрдә 14 кешенең гомере өзелгән. 7 кешене коткара алганнар.

БҮЛӘК ИЯЛӘРЕ БИЛГЕЛЕ!

«Ватаным Татарстан» газетасы «Нурмед» сәламәтлек үзәге белән берлектә 2023 елның беренче яртыеллыгына газетага язылучылар арасында өч сертификат уйнатырга вәгъдә иткән иде. Безнең укучыларыбыз һәрвакыттагыча актив катнаштылар. Һәркайсыгызга зур рәхмәт! Бүләк ияләрен жирәбә юлы белән сайлап алдык. Менә алар:

1. Ринат ВӘЛИЕВ
(Азнакай) – 9 төрле УЗИ + уролог консультациясенә сертификат.
2. Ләйлә ГЫЙЗӘТУЛЛИНА
(Әлки районының Иске Салман авылы) – 9 төрле УЗИ + гинеколог консультациясенә сертификат.
3. Нуриәхмәт АГЛЕЕВ
(Мамадыш районының Баскан авылы) – остеопат ярдәме.

Бүләк отучыларның **8 (905) 376-65-07** телефоны буенча элемтәгә чыгуларын үтенәбез. Бүләкләрне тапшыру вакытын һәм көнен хәбәр итәчәкбез.

Реклама 16+

ЭШЛЕГӘ КӨН ҖИТМИ

Корылыктан зыян күрүчеләргә ярдәм, Мамадыш сыры һәм Чистай хезмәтчәннәре. Казанга эш сәфәре белән Россия авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев килде. Татарстанда ул бу көннәрдә республикада узучы «Бөтенроссия кыр көне – 2023»тә катнашачак. Эшлекле очрашулар һәм сөйләшүләр исә аңа кадәр үк башланды.

Татарстан Хөкүмәт йортында узган очрашуда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Дмтирий Патрушев республиканың агросәнәгать тармагын үстерү юллары, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттыру һәм авылда яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту турында фикер алыштылар. Шул исәптән, быелгы корылык турында да сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, җәйге салкыннар һәм явым-төшемнәр булмау сәбәпле, терлек азыгы һәм бөртекле культураларның уңышы кимеячәк. Шуңа күрә зыян күргән хуҗалыкларга мөмкин кадәр ярдәм күрсәтергә кирәк, дигән фикер белдерделәр очрашуда. Федераль министр әйтүенчә, Татарстан авыл хуҗалыгы тармагы тотрыклы үсештә һәм нәтиҗәләрне яхшырта. «2022 елда республикада авыл хуҗалыгы тармагы буенча гомуми җитештерү индексы 126 процент тәшкил итте. Бу – ил күләмендә иң зур күрсәткечләрнең берсе», – диде Мәскәү кунагы.

Рөстәм Миңнеханов һәм Дмитрий Патрушев республика районнарына да эш сәфәре кылдылар. Мамадышта авыл хуҗалыгы министрына «Азбука сыра» заводын күрсәттеләр. Аерым алганда, Дмитрий Патрушевка предприятиене ташламалы кредит ярдәмендә яңарту эшләре турында сөйләделәр. Моның нәтиҗәсе буларак заводта продукция җитештерү күрсәткечен арттырырга ниятлиләр. Мәсәлән, быел биредә 15 мең тонна сыр җитештермәкчеләр. Мамадыш заводы үз продукциясен илнең 66 төбәгенә озата. Сырдан тыш биредә атланмай, эремчек һәм башка сөт ризыклары да ясыйлар.

Мамадышта Дмитрий Патрушев быел дәүләт программасы буенча төзелгән мәктәп-балалар бакчасын да карады. Ул мәктәп яшенә җитмәгән 120 балага һәм 240 укучыга исәпләнгән. Рөстәм Миңнеханов һәм Дмитрий Патрушевка уку йорты сыйныфларын, ашханә һәм актлар залын күрсәттеләр. Биредә сыйфатлы белем алу өчен барлык шартлар да бар, дип ышандырдылар кунакларга.

Чистай районында исә авыл хуҗалыгы министрын «Чистополье» холдинг компаниясе эшчәнлеге белән таныштырдылар. Әлеге компания Татарстанның иң күп авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләреннән берсе булып санала. Холдингка 12 авыл хуҗалыгы предприятиесе һәм 3 элеватор керә. 125 мең гектар җирләре бар, 7 меңгә якын баш мөгезле эре терлек тоталар. Шуның яртысы – савым сыерлары. Биредә бөртекле һәм май бирә торган культуралар, яшелчә, ит һәм сөт җитештерәләр. Быел шул исәптән, 167 мең тонна көзге бодай, 94 мең тонна кукуруз, 68 мең тонна рапс җыеп алырга ниятлиләр. Холдингта 2 меңнән артык кеше эшли. Уртача хезмәт хакы 50 мең сум чамасы тәшкил итә. Компания республиканың тармак уку йортлары белән дә хезмәттәшлек итә.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов һәм Дмитрий Патрушев заманча авыл хуҗалыгы техникасы паркын да карадылар. Биредәге «тимер ат»ларның барысы да навигация һәм ягулыкны контрольдә тоту җайланмалары белән җиһазландырылган. Бу – бизнесның нәтиҗәлелеген арттыра, чыгымнарны киметергә ярдәм итә, дигән фикер белдерде авыл хуҗалыгы тармагы хезмәтчәннәре.

КҮРЕП СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Түбән Камада – юл һәм транспорт, Болгарда – сәламәтлек, Урыссуда – үзара салым. Татарстан Дәүләт Советы депутатлары берьюлы 3 утырышны районнарга чыгып уздырды.

Түбән Камада Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше, Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетлары һәм әлеге комитетлар каршындагы эксперт советларының уртак утырышында транспорт мәсьәләсе турында фикер алыштылар. Депутатлар берничә предприятиедә булды, М7 федераль трассасының Чаллы һәм Түбән Каманы әйләнеп узу юлында Чулман аша күпер төзелешен барып күрделәр, беренче ярты еллыкка йомгак ясадылар һәм берничә закон проектын тикшерделәр. Күпер төзелешендә эшнең 20 проценты башкарылган. Инде киләсе елда анда техника йөри алачак. «Күпер тулы көченә эшли башлагач, Түбән Камада тормыш үзгәрәчәк», – диде Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Александр Тыгин. Бу төбәк өчен тагын бер әһәмиятле проект Тукай районында тормышка ашырыла. Биредә Дэн Сяопин исемен йөртәчәк логистик комплекс төзиләр. Ул атна саен Кытайдан ким дигәндә бер поездны каршы алып, аны кабат төяп җибәрер дип планлаштыралар. Эше дә, ашы да булачак.

Социаль сәясәт комитеты һәм комитет каршындагы экспертлар советының Спас районында узган күчмә уртак утырышында сәламәтлек турында сөйләштеләр. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов һәм Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова катнашында узган утырышка җыелучылар Тукай авылындагы фельдшер-акушерлык пунктын, Болгардагы поликлиника һәм үзәк район хастаханәсен барып күрде. Парламент вәкилләре белән сөйләшкәндә, район халкы терапевтлар санын арттыруны сорап мөрәҗәгать итте. Татарстан сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Альмир Абашев әйтүенчә, узган ел республикада 605554 кеше диспансеризация узган. Быел бу күрсәткеч 875 мең 295 кешегә җитәр дип ниятлиләр. Республика клиник онкология диспансеры мәгълүматларына караганда, 2022 елда диспансеризация нәтиҗәләре буенча 2422 кешедә онкология авыруы ачыкланган. Республикада беренчел медицина-санитар ярдәм күрсәтү кысасында «Мобиль поликлиника» эшли. Ел башыннан мобиль комплексларда республиканың төрле районнарында 12412 кешене тикшергәннәр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча быел республикада «сәнәгать диспансеризациясе» проекты гамәлгә ашырыла. 20560 кешене кабул иткәннәр, аларның 7 меңгә якынын җентекләбрәк тикшерәчәкләр. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов диспансеризация турында халыкның фикеренә колак салырга, моның өчен элемтә булдырырга тәкъдим итте. Шулай ук халык арасында аңлату эшен яхшыртырга да килештеләр. Чир яшерү юньлегә илтми.

Ютазы районында Бюджет, салымнар һәм финанслар һәм Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитетларының уртак күчмә утырышы узды. Анда катнашучылар үзара салым җыю турында фикер алыштылар. Билгеле булганча, дәүләт халыктан җыелган һәр сумга авылларда һәм район үзәге саналган бистәләрдә – 4, район үзәге саналган шәһәрләрдә – 3, ә Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы һәм Казанда 2 сум акча өсти. 2014 елдан бирле республикада халыктан 2,3 млрд сум акча җыелган, дәүләт шуңа 9 млрд сум өстәгән. Бу акча нигездә юл эшләре, зиратларны карап тоту, җирлек территориясен төзекләндерү, урамнарны яктырту, су белән тәэмин итүне оештыру кебек эшләргә тотыла. Җыелган акчаны файдалану мөмкинлеге булган эшләрнең аерым исемлеге бар. Татарстан Муниципаль берәмлекләр Советы Ассоциациясе башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Сергей Столяров әйтүенчә, җирле үзидарә органнары һәм халык бу исемлеккә законсыз чүплекләрне бетерү, паркларны карап тоту һәм башка юнәлешләрне дә өстәүне сорый. Депутатлар Министрлар Кабинетына бу мәсьәләне тикшерергә тәкъдим итте. Акчаның бәрәкәте булсын!

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткәннәре, Бөек Ватан сугышы елларында хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин иткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге өчен «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирергә:

«Радиоприбор» акционер җәмгыятенә;

«Татарстан агач эшкәртү комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 5 июль
№ 473

13 июльдә – соңгы утырыш

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының язгы сессиядәге соңгы – кырык бишенче утырышы 13 июльдә узачак. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Чараны Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин уздырды.

Депутатлар кырык бишенче утырыш кысасында 23 мәсьәләне, шул исәптән республиканың 14 закон проектын, 4 федераль закон проектын һәм Чувашия Дәүләт Советының закон инициативасын карап тикшерергә җыена.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, утырышның көн тәртибенә кертелгән республика закон проектларының 13е – беренче, берсе икенче укылышта каралачак. Аерым алганда, милеккә салым турында, салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучыларга салым ставкаларын билгеләү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү, кешеләргә бушлай юридик ярдәм күрсәтү турында республика законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан закон проектлары беренче укылышка әзерләнгән. Ә инде мәгълүмати системалар һәм мәгълүматлаштыру турында закон проекты (мәгълүмат системаларын булдыру, аларны куллану һәм яңарту мәсьәләләрен җайга сала) икенче укылышта карап тикшереләчәк.

Депутатлар Хөкүмәт сәгате кысасында транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифовның халыкны транспорт белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча чыгышын тыңлаячак.

Утырышта шулай ук парламентның быел беренче кварталдагы эшенә йомгак ясалачак. Бу җәһәттән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның чыгышы көтелә.

ЯУМАГАННЫ КАЯН АЛЫРГА?

ТАТАРСТАНДА ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ РЕЖИМЫ КЕРТЕЛДЕ

Татарстанда, эссе һава торышы урнашу һәм корылык булу сәбәпле, барлык районнарда да гадәттән тыш хәл режимы кертелде. Белгечләр фикеренчә, бу – көтелгән һәм аграрийлар өчен кирәкле карар.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров мондый карар кабул ителәсен атна башында ук әйтте. «Быел бик коры. Локатордан күзәтеп торабыз. Менә-менә яңгыр явар төсле, безнең якка килгән дә шикелле, ләкин читләтеп уза. Бу хәл елдан-ел күзәтелә. Атмосфера басымы бик югары», – диде ул журналистлар белән очрашуда. Министр әйтүенчә, гадәттән тыш хәл режимы кертелү аграрийлар өчен файдага булачак. Чөнки бу чәчүлек җирләрен иминиятләштергән компанияләргә җыеп ала алмаган уңышлары өчен акчаларын алырга ярдәм итәчәк.

– «Кызыл Шәрык», «Август» агрохолдинглары, гомумән, быел узган елга караганда күбрәк компанияләр җирләрен иминиятләштерде. Гадәттән тыш хәл режимы аларга файдага булырга тиеш, – диде министр.

Моннан тыш, әлеге режим районнардагы инвестицион һәм кыска вакытлы кредитларны озайтырга, һәм шулай ук башка бурычларны кәрарга мөмкинлек бирәчәк. Шул ук вакытта министр иминият компанияләре белән эшләүнең бик авыр булуын да яшерми.

– Корылык безнең территориядә ел аралаш кабатлана башлады. Быел да үзенчәлекле ел килде. Суыгы да, корылыгы да бар, – дип шәрехләде бүгенге вазгыятьне министр урынбасары Ленар Гарипов. – 2010 елгы бик көчле корылык вакытында 670 мең тонна ашлык җыеп алынган иде. Бу агрономнарга үзенә күрә бер хәбәр булды. Шул елдан соң хуҗалыклар актив рәвештә үсемлекләрне яфрактан тукландыруга күчте. Ашлык культураларына килгәндә, бүгенгә күпьеллык үләннәрнең беренче каты чабылып бетте диярлек. Ләкин бу безгә терлек азыгының нибары 25 процентын гына әзерләргә мөмкинлек бирде. Икенче катына да өмет юк. Яңгыр яуган очракта гына күпмедер җыеп алырга мөмкин булачак. Кукурузга да әле үсәр өчен вакыт бар. Тик шулай ук яңгыр булуы кирәк. Кайсы хуҗалыкның үз запасы юк, күрше төбәкләр белән сөйләшүләр алып барырга кирәк. Без дә бу мәсьәләне катгый контрольдә тотабыз.

Мөслим районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ренат Вәлиев сүзләренчә, аларда чәчүлек мәйданнарының 21 проценты иминиятләштерелгән. Болар өч зур компания – «Август Мөслим», «Туган як» һәм «Намус» агрофирмаларының җирләре.

– Гадәттән тыш хәл режимы кертелү аларга акча алырга мөмкинлек бирергә тиеш инде. Вазгыятьне истә тотып, башкаларга нинди дә булса ярдәм булырмы-юкмы, әлегә билгесез. Безгә өметләнергә генә кала, – диде ул.

Тик хуҗалыклар иминият акчасын алуны сират күперен кичүгә тиңлиләр. Шуңа күрә бер тапкыр авызлары пешкән хуҗалыклар моны эшләүне бөтенләй кирәк дип тапмый. Әйтик, Саба районы Икшермә авылының зур фермеры Зөфәр Мөхәммәтшин хуҗалыгында 1900 мөгезле эре терлек, 2594 гектар сөрүлек җирләре бар. Ләкин ул чәчүлек җирләрен иминиятләштермәгән.

– Без быел игеннәрне иминиятләштермәгән идек, чөнки аның акчасын алу бик катлаулы. 2014 елдан бирле ала алганыбыз юк. Һәм безнең кебек хуҗалыклар бик күп. Тугыз ел суд юлында йөрибез, әле дә булса очына чыгып булмый, – диде ул.

Шулай да республикада гадәттән тыш хәл режимы кертелүнең зыяны юк, дип белдерде.

– Бездә өч айга 37 мм яңгыр яуды. Норма буенча бер айның яртысы кадәр генә дигән сүз бу. Шуңа күрә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәч, бәлки, хуҗалыкларга нинди дә булса ярдәм булыр. Азык әзерләү бик авыр бит. Кукуруз да бик начар үсә. Күп кенә хуҗалыклар, читкә чыгып, азык әзерли башлады. Без үзебез әлегә чыкмадык. Узган елгы запаслар да бар иде. Бәлки, шул җитәр дә. Әлегә хәл итеп бетермәдек, – диде Зөфәр Мөхәммәтшин.

Чүпрәле районының «Чынлы» хуҗалыгы җитәкчесе Барис Гафуров алда ни көтәсен фаразлый алмады.

– Әле бу турыда игълан ителәр генә бит. Пленар утырышта ни дип әйтерләр инде. Без үзебез дә әлегә берни белмибез. 2010 елда да, көчле корылык булу сәбәпле, гадәттән тыш хәл режимы кертелгән иде. Ул вакытта без бик зур ярдәм алдык. Гәрчә иминиятләштермәгән булсак та. Быел да иминиятләштермәдек. Чөнки кулда кәгазь булса да, берни алып булмаган чак та бар иде, – диде хуҗалык җитәкчесе.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Вазгыять

2010 елда да республикада барлык районнарда гадәттән тыш хәл режимы кертелгән иде. 2021 елда ул Татарстанның 38 районында игълан ителде.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, быел, узган ел белән чагыштырганда, иминиятләштерелгән чәчүлек җирләре 13,2 процентка (360,3 мең гектар) арткан. Шул исәптән гадәттән тыш хәл режимы программасы буенча уҗым культуралары – 46,4 мең гектарда, ә язгы культуралар 101 мең гектарда иминиятләштерелгән.

Илдар Мөхәммәтжанов

Фараз

Татарстанда бик коры һәм эссе һава урнашты. Көндез һава температурасы +28...+31 градуска кадәр җитә. Якын араларда эсселек бөтенләй дә +36 градуска җитәргә мөмкин.

Гидрометеоүзәк мәгълүматлары буенча, шимбә һәм якшәмбе – 8–9 июльдә һава торышы сизелерлек үзгәрмәячәк. Явым-төшем көтелми. Көндез һава температурасы +29...+35 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә +17...+22 градус.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, дүшәмбе – 10 июльдә көнбатыш районнарда кыска вакытлы яшенле яңгырлар яварга мөмкин. Көндез +28...+33, көнчыгыш төбәкләрдә +36 градуска кадәр. Төнлә +17...+22 градус. Сишәмбе – 11 июльдә дә кыска вакытлы яшенле яңгырлар явып үтү ихтималы бар. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +24...+29 градуска, көнчыгыш районнарда +30...+35 градуска кадәр күтәреләчәк.

kamazmaster.ru

Хәерле сәгатьтә!

БАШКАЛАДА 13 НЧЕ «ЕФӘК ЮЛЫ» РАЛЛИ ЯРЫШЫ СТАРТ АЛДЫ

Кызык та, мавыктыргыч та, авыр да булачак. «Ефәк юлы» ралли ярышы катнашучылары узыштан әнә шуны көтә. Шул ук вакытта үзара ярдәмләшү турында да онытмаячакбыз, диләр. Экипажлар, тикшерү узып, Казанның Меңьеллык мәйданыннан ун көнлек зур юлга кузгалды.

Юл фатихасын исә «Ефәк юлы» проекты җитәкчесе Владимир Чагин бирде.

– Иң элек катнашучыларга рәхмәт әйтәсе килә, – диде «Дакар» ярышлары герое. – Алар техник, финанс, административ сорауларны хәл итеп килде. Нинди юл узуларын алар гына белә дә, без беләбез. Катнашучыларның иганәчеләренә дә рәхмәт. Техник спорт төрләре – кыйммәткә төшә торган чаралар ул. Бизнес ярдәме бу очракта бик мөһим. Төбәк җитәкчеләренә дә рәхмәт. Былтыр 10 төбәкне узсак, быел алар – 13. Маршрутны булдыру, оештыруда аларның роле зур.

Чагин бу ярышны төбәкләр һәм катнашучылар арасында сузыла торган дуслык җебе дип атады. Монда төрле төбәкләр генә түгел, төрле милләтләр дә берләшә.

– Алда мавыктыргыч юл көтә. Оештыручылар бу 10 көн һәркемнең исендә калсын өчен тырышты, – диде Владимир Чагин. – Катнашучыларга шуны телим: сезнең турында язар, төшерер өчен яхшы сәбәпләр генә бирегез!

Узышта «КамАЗ»ның яңа төр техникасын да сынаячаклар. Йөк машиналары зачетында «UralMotorSport» командасы чыгыш ясаячак. Пилот Сергей Куприянов моңа сөенүен белдерде.

– Йөк машиналары зачетында чыгыш ясау быел җиңел булмаячак. Сүз уңаеннан, минем энекәшем – штурман Александр Куприянов ярышта катнаша алмый. Катнашучылар составында яңа команда барлыкка килү куандырды, – диде ул.

Сергей Куприянов әйтүенчә, ярышларда үзара ярдәмләшү сыйфаты да саклана. «Команда белән эшләү, ярдәмләшү, бердәмлек – «КАМАЗ-Мастер»ның күпьеллык җиңүләренең сере әнә шулардыр», – дип тә уртаклашты спортчы.

Халыкара чараларда катнашу мөмкин булмагач, үз ралиебыз булу – куаныч. Ралли-рейд буенча күп тапкырлар Россия чемпионы булган Владимир Васильев шулай дип белдерде.

– Хәзерге вазгыятьтә Россия буенча гына узышабыз, халыкара узышлар юк. Быел яңа юлдан узабыз. Бу – безнең өчен дә яңалык. Юл катнашучыларга ошар дип уйлыйм, – диде спортчы.

«КАМАЗ-МАСТЕР» ЭКИПАЖЫ СОСТАВЫ

Экипаж №300: Дмитрий Сотников (пилот) – Руслан Әхмәдиев (штурман) – Илгиз Әхмәтҗанов (механик);
Экипаж №301: Андрей Каргинов – Иван Мальков – Вадим Әхмәтов;
Экипаж №303: Эдуард Николаев – Евгений Яковлев – Богдан Кәримов;
Экипаж №305: Сергей Куприянов – Дмитрий Никитин – Иван Татаринов;
Экипаж №307: Хоу Хоннин – Шэнь Синь – Сергей Кренев.

Сан

• Ралли-рейд **9** этаптан тора, Россиянең **13** төбәген колачлый. Маршрутның гомуми озынлыгы – **5247** чакрым. Шуның **2277**се – махсус спорт участоклары.
• Катнашучылар барлыгы **200** мең литр ягулык кулланачак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Әйтеп кенә бактым

Гаҗәп хәлләр

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Борынгы греклар телендә барлыкка килгән «мистика» (серле) дигән сүз бүген дә шактый еш кулланыла. Кулланылмас иде, без әледән-әле гаҗәп, сәер хәлләргә тарый торабыз. Бер уйлаганда, алар очраклылык кебек тоела, әмма шул ук вакытта ниндидер илаһи көчләргә буйсыналар кебек.

Без быел корбан чалмадык. Хатын: «Иртүк торып, гает коймагы пешерермен дә, кара-каршы утырып, матур итеп чәй эчәрбез», – диде. «Ярар, – мәйтәм, – мин иртүк торып гает вәгазен тыңлармын, гает намазы укырмын. Иртәнге өченчеләрдә уянырга кирәк инде», – дип сөйләнә-сөйләнә йокларга яттым.

Әллә өнемме, әллә төшемме дигәндәй, кемнеңдер йөземә иелеп: «Риман, торасыңмы?» – дип дәшкәненә уянып киттем. Әлеге «кемдер» бераз хатыныма охшаган яшь кенә, матур гына хатын иде. «Хәзер торам», – дидем дә күземне ачтым, әмма бүлмәдә берәү дә юк. Ә сәгать өченче унбиш минут. Тәһарәт алып, телевизор кабыздым. Казанда яңа ачылган Утыз-Имәни исемендәге мәчеттә Корбан гаете вәгазе башланырга тора. Күңел биреп, вәгазь тыңладым, имамга оеп, намаз укыдым, күңелдә әйтеп бирә алмаслык ниндидер җиңеллек сиздем.

Гает коймагы белән тәмләп чәйләр эчтек тә дачага җыена башладык. «Корбан чалу», «корбан ашы» дигән сүзләр барыбер бераз күңелне кытыклап торды үзе. Хатын минем ниләр уйлаганны сизде, ахрысы: «Бакчага баргач та гает коймагы белән иркенләп чәй эчәрбез», – диде. «Анысы шулай инде»дән уза алмадым. Корбан ашы күңелгә керә генә бит! Ичмасам, бүген бакча күршеләре белән дә очраша алмаячакбыз. Алар кичә килеп кунып, бүген иртәнге җиделәрдә Казанга китәргә тиеш иде.

Бакчабыз – Биектау районында. Анда барышлый Биектау станциясендә яшәүче дустыбыз Солтаннарга кагылмый китмибез. Солтан да, хатыны Диләрә дә гомер буе балалар укытып, хәзер, үзләре әйтмешли, «лаеклы ялда». «Лаеклы яллар»ына кош-корт асрау һәм безне авыл йомыркасы белән тәэмин итү дә керә. Һәрвакыттагыча: «Солтан, тавыкларыгыз исән-сау-мы?» – дип шалтыраттым. «Килегез, кил! Сез дигәндә….» – дигән була. Йомыркалар алдык та, Солтан: «Хәзер бер минут кына көтегез!» – дип, өенә кереп китте һәм безгә… корбан ите алып чыкты. «Насыйп ризык тешеңне сындырып керә», – диюләре шушыдыр инде. Хатын юл буе: «Алла, ите әйбәт! Их, күршеләр генә юк, корбан ашы пешереп бергә-бергә ашар идек…» – дип сөйләнде.

Килеп җиттек. Машинадан чыга гына башлаган идек, егылып китә яздык: капка төбендә, елмаеп, күршеләребез Фоат белән Фәридә басып тора. Уйлаганнар-уйлаганнар да, бәлки, без килер дип, көтәргә булганнар. Дуслар биргән корбан итеннән аш пешереп ашадык. Фоат белән мин генә түгел, хәтта ике Фәридә дә (хатыннарыбыз – адашлар): «Мондый тәмле аш ашаган юк иде әле!» – диделәр. Язганнарым очраклы хәл микән? Әллә күңелдәге уйларны илаһи көчләр укып, безгә ярдәм ителәрме? Әле бит бакчага барыйкмы икән, юк микән, дип икеләнеп тә торган идек. Әмма кемдер безне барырга өндәде. Күңел ниндидер куанычлы мизгелләр көтә кебек иде.

Инде хәзер уйлап утырам: кеше һәр гамәлен алдан ниятләп яшиме, әллә аның белән язмыш идарә итәме? Итсә, язмыш кем кулында?

Тагын бер гыйбрәтле хәл искә төште әле. Күптән түгел, танышымның әнисе бакыйлыкка күчте. Озак еллар аралашып, хәл-әхвәл белешеп яшәдек без, әмма әнисе – Мәрзия әбинең үлеме безнең өчен генә түгел, улы, килене өчен дә көтелмәгән булган. 96 яшьтә иде Мәрзия әби, аякта иде әле, хәленнән килгәнчә өй эшләрен эшләп йөрде. Беркөнне: «Улым, киленем, мунча ягыгыз әле, мин иртәгә үләм», – дигән.

Аның сүзенә, әлбәттә инде, ышанмаганнар. «Әни, юк-бар сөйләмә!» – дигәннәр. «Бер дә юк-бар түгел. Яшисен яшәдем, чама да белергә, нәфесеңне дә тыярга кирәк. Шундый озын, матур гомер биргән өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт», – ди икән Мәрзия әби. Улы да, килене дә дәшмәгән, әби шәрәрта дип уйлаганнар. Ә мунчалар кереп, кичке ашны ашагач, әби: «Иртәгә төш вакытларында өйдә булыгыз!» – дигән. Һәм икенче көнне төш вакыты җиткәндә, ул, бераз хәл алыйм дип, диванга барып яткан да тыныч кына бакыйлыкка күчкән.

Танышым, миңа шалтыратып: «Күңел ышанмаслык хәл, әле дә аңыбызга килә алмыйбыз», – дигән иде. Минем дә акылга сыймый бу. Көнен, сәгатен әйтеп, тыныч кына китеп бар инде?! Мәрзия әби белән булган хәлне дусларга да, дин әһелләренә дә сөйләдем. Барысы да: «Изге җан булган, әүлия булган», – диделәр. Ә мин исә һаман аптырашта.

АЛТЫН СТАНДАРТ КАЙТЫРМЫ?

Агымдагы атнада мәгълүмат кырына БРИКС илләренең алтын белән тәэмин ителгән уртак валютасын булдырырга җыенулары турында хәбәр чыкты. Гади кеше өчен берни аңлатмаса да, хәбәр әһәмиятле. Чынлап та, шундый валюта булдырылса, бик ышанычлы акчага әйләнер иде. Без яшәгән сикәлтәле һәм давыллы бу елларның төп проблемасы бит – акчага ышаныч булмау.

Кайсы гына кәгазь акчаны алып карама, инфляция тарафыннан ашалып, көннән-көн юкара, сатып алу сәләтен югалта. Кесәдә кәгазь акча тоту аны өлешләп югалтуга тиң. Банк депозитлары да югалтуларны каплый алмый. Тапкан байлыкны саклау ниятеннән, кешеләр криптовалюталар уйлап чыгарып карадылар. Башта фантастик рәвештә кыйммәте үскән биткоиннар да, бер үргә сикереп, бер түбәнгә мәтәлеп, ышанычны югалттылар. Биржа уеннары да бик хәвефле: бүгенге олигархны иртәгә теләнчегә әйләндерә алалар. Эшләп алганыңны тупламый гына безнең кебек гади кешегә фатир алу, машина юнәтү мөмкин түгел диярлек, чөнки бәяләр артыннан куып җитә алмаячаксың. Шуңа күрә кешеләр кредитка алу белән мавыга. Кредит түләүче үз хәлен үзе генә белә.

Инфляциянең механизмы исә бик гади: Үзәк банклар чамасыз күп акча басалар һәм шуны процентлы кредит итеп өләшәләр. Алтын белән тәэмин ителгән валюта ул мөмкинлекне юкка чыгара, чөнки акчаны банктагы алтын запасы күләмендә генә баса аласың. Кәгазь акчадан туйса яисә аның ышанычлы булуына шик керсә, банкнот иясе аны алтынга алыштырып бирүләрен таләп итә ала һәм аның таләбе берсүзсез канәгатьләндерелә. Акча басу мөмкинлеге чикләнү сәбәпле, инфляция дә юкка чыга диярлек. Товар кытлыгы булганда, бәяләр күтәрелергә мөмкин, әлбәттә, әмма хәзерге технологияләр теләсә нинди товарны күпләп җитештерү мөмкинлекне биргәнлектән, бәя бик тиз кире үз хәленә әйләнеп кайтачак. Хәзерге кебек барлык товарларның бердәм рәвештә бәяне югарыга чөюләре алтын белән тәэмин ителгән валюта шартларында мөмкин түгел диярлек. Кесәңдә алтын белән тәэмин ителгән банкнот булганда, син теләсә кайсы илгә курыкмый бара аласың. Доллар-евро сатып алып, аның өчен комиссия түләп мәшәкатьләнергә кирәкми. Кайчандыр булган андый шартлар. Беренче Бөтендөнья сугышына кадәр күп кенә илләрдә алтын белән тәэмин ителгән акчалар йөргән. Россия патшасының акчасы да шулай ук алтын кыйммәткә ия булган. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң доллар шул рольне алды һәм алтын стандартка ия булган Америка кәгазе бөтен дөнья өчен диярлек түләү чарасына әверелде… Хәзер долларның андый сәләте юк, билгеле, әмма инерция буенча ул барлык илләр өчен дә акча функциясен башкаруын дәвам иттерә. Алтын стандарттан азат булган доллар шулай ук инфляциягә бик нык бирешә. Моннан илле ел элек бер долларга сатып алган товарны хәзер ун долларга да ала алмыйсың инде.

Акчага ышаныч бетү – зур түнтәрелешнең башы ул. Гражданнар сугышыннан соң, ачлык һәм ялангачлык кочагында бәргәләнгән советлар илендә икътисадны торгызу өчен большевиклар ни эшлиләр әле? 8,6 грамм алтын белән тәэмин ителгән «червонец» дигән ун сумлык акча кертәләр. Николай патша унлыгы да нәкъ шундый ук кыйммәткә ия булган. Червонец кертелгәч, сәүдә җанлана, хосусый бизнес үсә башлый… БРИКС илләре дә, безне шатландырып, алтын белән тәэмин ителгән акча басарга ниятлиләр. Безнең өчен икеләтә шатлык бу, чөнки Россия – БРИКСның төп илләреннән берсе.

Автор шушы урында сөенечне туктата һәм укучыны кара чынбарлыкка тартып төшерә. БРИКСның алтын стандарты тормышка ашмаячак. Без – дилетантлар, әлбәттә, ә алтын белән тәэмин ителгән акча идеясен профессиональ сәясәтчеләр һәм финанс белгечләре алга этәрә. Алар үз эшләрендә, русча әйтсәк, «собаку съели». Әмма бу юлларны язучы дилетант булса да, үз эшенең остасы булган профессионалларга каршы чыга һәм аларның карашларын кире тибәрә, чөнки бездә әлегә берникадәр аек акыл сакланып калды. Хәзерге зур сәясәт әһелләре исә, интеллектуаллар булуга карамастан, акылларын югалттылар. Банк әһелләренең акылларын югалтуларына бер генә мисал китерик. Халыкара финанслар үзәге булган Бөекбританиядә банкирлар гейлар һәм лесбиянкаларга каршы булучыларның банк хисапларын бикли. Банк хисабында бик күп акчаң булса да аны файдалана алмаячаксың ягъни. Yorkshire Building Society банкы, мәсәлән, рухани Ричард Фотергиллның банк хисабына йозак салган. Фотергилл банкирларның эше ЛГБТны яклау түгел, ә «акча белән идарә итү» дигән сүзләр ычкындырган булган. Кайчандыр Европарламент әгъзасы булган Хенрик Овергард Нильсен исемле әфәнденең дә банктагы акчасын шундый ук язмыш көтә икән. Болар хакында The Telegraph һәм The Times басмалары хәбәр итә. Банкирлар – кайда гына яшәмәсеннәр, бер үк болын җиләкләре. Процент капиталы белән җенси азгынлык арасында уртаклык шактый. Беренче карашка гына бер-берсеннән ерак тора кебек алар.

Алтын белән тәэмин ителгән БРИКС акчасына әйләнеп кайтыйк. Ни өчен без аны мөмкин түгел дип саныйбыз? Дәүләтләрнең алтын белән тәэмин ителгән уртак акчасын булдыру – тормышка ашмаслык катлаулы эш. Кәгазь акчаны алтын стандарт белән тәэмин итү өчен, зур күләмдә алтын запасы кирәк. Аны каян алачаклар? БРИКСка кергән илләрнең гомуми алтын запасы – 5,5 мең тонна. Бу, бердән, бик аз, икенчедән, ул дәүләтләрнең үз алтын запасларын уртак казанга салачакларына бик шикләнәм мин. Ярый, хуш, салдылар, ди. Шул алтын күләмендә кәгазь акчалар бастылар, дип тә уйлыйк. Берничә миллиард кешегә өләшергә ул акча аз булачак. Кулына алтын белән тәэмин ителгән кәгазь тотуга, кешеләрнең байтагында аны алтынга алыштыру теләге туачак. Кәгазь – кәгазь инде ул, алтын – Африкада да алтын. Әйтик, берничә йөз миллион кытайлы һәм россияле, кәгазь акчаларын алтынга алыштырып, сандыкка салып куйсыннар ди. Дәүләтләрнең алтын запасы шәхси затларның сандыгына күчә дигән сүз бу. Сез инде, кешеләр алай эшләмәячәк, чөнки тотарларына акча кирәк булачак, диярсез. Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамланып килгәндә, АКШның алтын запасы 20 мең 205 тоннага җитә, чөнки американнар сугыш коралларын алтынга саталар. Американың алтын запасы бар дөньядагы алтын запасының 70 процентын тәшкил итә. Мондый байлык алтын доллар кертергә мөмкинлек бирә дә инде һәм доллар бердәнбер резерв валютасы буларак дөньяны яулый. Бер трой унциясе алтынны рәхәтләнеп 35 долларга алыштыру мөмкин була. 1971 елга, якынча 25 еллап вакыт үткәч, АКШның алтын запасы 8133 тоннага гына кала. Шуннан соң Президент Ричард Никсон бер селтәнүдә долларның алтын стандартын юкка чыгара. Бик зур тавыш куптара бу, әмма ул чакта Америка гаҗәп зур хәрби куәткә ия дәүләт була: тавышланып, ерак китә алмыйсың. БРИКСның алтын запаслары белән ни булачагын чамалый торгансыздыр.

Хәзерге финанс системасы алтын стандартны күтәрә алырлык түгел. Процент капиталы яшәгәндә, хәзерге кредитларны тәэмин итү өчен Җир шары зурлыгында алтын да җитмәячәк. Берничә йөз Җир шары зурлыгындагы алтын да аз булачак хәтта. Шуңа күрә алтын стандарт турындагы идея матур хыял булып калачак. Профессионаллар шул хыяллары белән яшәсен әйдә, ә без, дилетантлар, андый хыялларга бирелмибез. Бүген яшәүчеләрнең озын гомерләре бөтен планетада алтын һәм көмеш акчаның бердәнбер түләү чарасы булып хезмәт итүен күрәчәкләр әле. Тик ул чакта бөтенләй башка система һәм башка законнар хакимлек итәчәк.

Теманы төгәлләгәч, тагын бер дәлил өстәргә кирәк дип тапты әле автор. Акча һәрвакытта да җитми бит ул. Алтын стандарт кертелсә дә, кәгазь акчаны барыбер аның алтын эквивалентыннан күбрәк басачаклар. Кешеләр интуитив рәвештә банкирларның нинди жуликлар икәнен тоялар һәм кәгазь банкнотны физик алтынга алыштырып куюны хәерлерәк күрәчәкләр. Нәтиҗәдә алтын стандарт гасыры берничә айда төгәлләнәчәк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Эльвира ВӘЛИЕВА

АКЧА ҖӘЙНЕ ЯРАТА

Рәхәт тә соң җәй көне! Җылы кием сатыш аласы юк, коммуналь хезмәтләр өчен түләү кими, җиләк-җимеш, яшелчәсе дә бакчада гына үсә. Беренче карашка, чыгымнар да азрактыр кебек. Тик болай фикер йөртергә ашыкмагыз. Баксаң-күрсәң, елның башка фасыллары белән чагыштырганда җәй кесәгә ныграк та суга икән әле. Җәйге чыгымнарны «ВТ» хәбәрчесе дә исәпләде.

Китереп бирмиләр

Гөлия һәм Дамир Гарифуллиннар Биектау районының Шигали бистәсендә үз йортларында яшиләр.

– Казандагы ике бүлмәле фатирдан үз йортыбызга күчкәнгә өч ел, – ди гаилә башлыгы. – Шуннан бирле җәй ул – безнең өчен төзелеш чоры. Йортлы булган беренче җәйдә әле өй салынып бетмәгән иде, былтыр гараж җиткердек, быел план буенча мунча. Алдагы берничә җәйгә җитәрлек эш бар әле. Койма-капканы рәткә китереп бетерергә, беседка төзергә, бакчаны каларга кирәк. Әлегә бакчада бер теплица һәм өч-дүрт төп җимеш агачыннан башка берни юк. Кыш көне диванда кырын ятканда гына рәхәт ул. Җәй көне чыгымнар бермә-бер арта. Мунча бурасы гына да 350 мең сумга төште әнә.

Казандагы төзелеш материаллары сатучы кибет хезмәткәре Ришат Сәлахиев әйтүенчә, хәзер аларда – «урак өсте».

– Җәй көне төзелеш һәм ремонт өчен кирәкле материаллар сатып алучылар бермә-бер арта. Якын арада кибетнең эш вакытын ике сәгатькә арттыру турында да уйлана башладык инде. Күбрәк штукатурка, шпаклевка кебек коры катнашмалар, түбә һәм идәнгә җәю материаллары, обойлар һәм төзелеш инструментлары сорыйлар. Узган ел белән чагыштырганда, төзелеш материалларын запас белән алучылар күбәйде. Бу – пандемиягә кадәр дә шулай иде. Соңгы арада гына бәяләр әллә ни артмады. Хәер, алар ел ярым – ике ел дәвамында шактый кыйммәт инде. Кибеттә сатылучы товарларның 90 проценты үзебезнең илдә җитештерелгән. Шуңа күрә бернинди кытлык юк, – ди сатучы.

Аналитика агентлыкларының берсе исәпләп чыгарган: бу җәйдә, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, тырма, себерке, су сипкеч ише бакча кирәк-яраклары да 29 процентка күбрәк сатылган. Бакчачылар бер баруда кибеттә уртача 2 мең сум акча калдыра, ди.

Авыл кешесенең исә бакчада гына түгел, ишегалдында да эше җитәрлек.

– Бер нәрсәне бушка китереп бирмиләр, үзеңә тырышырга кирәк. Кышка ит тә булсын, бераз акча да керсен дип, җәй башында ук 62 мең сумга берәр айлык өч бозау сатып алдык. Печәнне үзебез җыябыз. Җәйгә ашарга дип, һәркайсы 360 сумнан берәр айлык 30 бройлер чеби кайтарттык. Аларга ашарга витаминлы көрпәнең бер капчыгы 1200 сум тора. Шул ризыкта гына тотсаң, 30 чебигә бер капчык өч көнгә дә җитми. Ит алтын бәясенә төшәчәк. Мин көрпәне пешкән бәрәңге белән изгән бодай өстенә, күз алдарга дип, бераз сибеп җибәрәм. Шул рәвешле бер капчыкны бер атнага җиткерәм. 40 көннән бройлерлар суярлык булды. Авылда тавык итенең килосын 330 сумнан саталар. Без исә, тоткан акчаны санамыйча, итне үзебезнеке дип ашыйбыз. Җәй көне авылда эш тә, аңа бәйле чыгымнар да бик күп, – ди Яшел Үзән районының Күгеш авылында яшәүче Зәмирә Джороева.

Ял итәсе килә

Җәен укучы балалар да өйдә бит әле. Мәктәп булмагач, аларны ашатырга, киендерергә, күңелен күрергә кирәк.

Сораштыру

ЧЫГЫМНАРЫГЫЗ АРТАМЫ?

Җәй көне эш тә, аңа бәйле чыгымнар да күбрәк	59%
Юк, җәй көне кием-салым да азрак кирәк бит	18%
Мин җәен дә, кышын да акча күп тотам	23%

«ВТ»ның «ВКонтакте» социаль челтәрендә үткәргән сораштырудан



Гөлназ Гыйләҗева

«Сәхнә» журналы мөхәррире Зөлфия Гыйльметдинова бу көннәрдә кызын җәйге лагерьга җыендыру мәшәкатьләре белән йөри.

– Баланы лагерьга озату – җәйнең иң зур чыгымнарының берсе, – ди әни. – Мин кызыма кием-салымны, лагерьга баруын да исәпкә алып, җәй башында ук алып куйдым. Кыз кеше булгач, моңа бәйле чыгымнар күбрәк тә әле. Эчке кием-салымга гына да 2 мең сум тирәсе акча китте. Кызым футбол белән шөгыльләнә. Шуңа күрә киемнең дә төрлесе кирәк. Чәч тузмасын өчен һәр формага туры килүче резин тасмага кадәр уйланылган булырга тиеш. Аңлашыла ки, күбрәк спорт стилендә киенсә дә, кыз баланың көяз буласы килә. Әнә шундый вакытәяккә генә дә 1 мең сум тирәсе акча китте. 3 мең сумга яңа «бутсы» сатып алдык. Гомумән дә, футбол белән шөгыльләнгәндә аяк киемен бик еш алмаштырырга туры килә. Чөнки кроссовка аякка тап-таман булырга тиеш, «бераз үскәч тә киярлеге» белән уйнап булмый. Ә бала аягы тиз үсә. Лагерьга юллама өчен 13 мең сум түләдек. Медицина белешмәләре 1 мең сум тирәсенә төште. Акча күп кирәк, кыскасы. Тик баланың көтеп алган ялы өчен берни жәл түгел. Яраткан шөгыле бар икән, без бик риза. Чөнки интернет дөньясы балаларны шулкадәр үзенә тартып алды ки, шуннан бераз бушанып тору, игътибарны башка нәрсәгә юнәлтү мөһим. Төрле гаиләләр бар, билгеле. Ике баласы футболга йөргән әти-әниләр арасында лагерьга бәйле икеләтә чыгымнарны күтәрә алмаучылар да булды.

Балага гына түгел, әти-әниләргә дә ял кирәк. Күпчелек җәйне диңгез кояшыннан башка күз алдына да китерми. Гүзәлем һәм Салават Миңнехановлар кызлары Мәдинә белән әле күптән түгел генә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә ял итеп кайткан.

– Без Башкортстанга елгада йөзәргә барырга җыенган идек, тик килеп чыкмады. Ә кая да булса барып ял итеп кайтасы килә. Шуңа күрә уйлаштык та Дубайга киттек, – ди Салават Миңнеханов. – Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә тәүге тапкыр баруыбыз. Алты көн буе экскурсияләрдә йөрдек. Чүлдә дөяләргә дә утырдык, дөньядагы иң зур мәчетләрнең берсендә дә булдык. Ял бик ошады. Чыгымнарга килгәндә, ул ялны ничек оештыруыңа һәм аннан ниләр өмет итүеңә бәйледер, минемчә. Арзанракка да читкә китеп рәхәтләнеп ял итеп кайтырга мөмкин. Ә шәхсән минем өчен иң яхшы ял ул – Азнакайда. Чөнки туган яктан уңай энергия алып киләсең. Анда тыныч, ашыгу-кабалану юк. Дөньяны күрергә дә кирәк, әлбәттә. Мәсәлән, Дагыстан, Чечня, Азәрбайҗан, Үзбәкстанга бик тә барасыбыз килә. Җәйгә планнар зур, кыскасы.

Җәйге ялның бәясе дә билгеле. Бөтенроссия халык фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыру мәгълүматларыннан күренгәнчә, былтыр Россиядә яшәүче һәркем җәйге чорда ял итүгә уртача 38605 сум акча тоткан. Чагыштыру өчен: пандемиягә кадәрге 2020 елда әлеге сан 32 мең сумга да тулмаган. Чит илгә чыгучыларның чыгымнары исә – 46 мең сум чамасы. Сораштыруда илнең барлык төбәкләре дә катнашкан. Ялга иң зур чыгым тотучылар – зур шәһәрләрдә яшәүчеләр, билгеле. Былтыр аларның җәйге ялы бер кешегә якынча 56 мең сумга төшкән.

Кояш хакы

Дизайнер Гөлшат Нуриева әйтүенчә, көз-кыш айларыннан аермалы буларак, җәй көне һәркемнең, ә гүзәл затларның бигрәк тә, матур буласы килә.

– Кыш көне без нәрсә киябез? Бәйләнгән кофта, җылы чалбар һәм калын куртка. Кәеф яхшы булганда гардеробтан пәлтә яки тун чыгарга мөмкин. Тик бу ел саен алмаштыра торган киемнәр түгел. Шул ук пәлтәне, мәсәлән, берничә сезон кияләр. Гомумән, кышын тышкы кыяфәт ягыннан ничектер башкалардан аерылып торасы килми. Ә менә җәй көне, киресенчә, күңел гел яңа күлмәк тели. Итәк-чалбар киясеңме, әллә шортымы, сайлау мөмкинлеге зур. Һәр яңа образга туры килә торган аяк киеме дә кирәк. Шуңа күрә, һичшиксез, җәй көне кием-салымга акча күбрәк тотыла, – ди белгеч.

Җәй көне акчаның исәбе югала, ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин.

– Гомуми статистика мәгълүматларына караганда, кыш айлары иң чыгымлы чор булып санала. Чөнки без барыбыз да Яңа ел табыны күпмегә төшкәнен, кышкы каникулда ял итү бәясен беләбез, ә шул ук Сабан туе үткәрү бәясен яки балаларның җәй буе ничә сумлык газлы су эчүен беркем дә санамый. Чынлап торып исәпли калсаң, без бүген күбрәк чыгым тотабыз. Җәй көне халык ял итеп калырга тырыша һәм моның өчен акчасын кызганмый. Табигатькә дә ешрак чыгасың, шашлык та күбрәк ашыйсың дигәндәй. Урам чатлары яшелчә, җиләк-җимеш сатучылар белән тулды. Җәй төзелеш чоры икәнен дә истән чыгарырга ярамый. Бу вакытта күчемсез милек базарында гына тынлык күзәтелә. Җәй, гадәттә, фатир сату-алу вакыты түгел. Сәбәбе бик гади: кесәдәге акчаны торак шартларын яхшыртуга түгел, ә ялга тоталар. Җәй көне кесәдәге акчаны тотуга караш үзгәрә, – ди белгеч.

НИЧЕК САКЛАП ТОТАРГА?

Бәйсез финанс киңәшчесе Артур ЗАКИРОВтан 5 киңәш

1 **Ашау-эчү.** Җәй көне күбрәк сезонлы яшелчә, җиләк-җимеш ашарга тырышыгыз. Әгәр авылда яки үз йортыгыз белән яшисез икән, димәк, помидор-кыярны, алма-чияне бакчада үстерергә дә мөмкин. Бераз тырышлык кына кирәк. Гомумән, җәй көне сезонлы яшелчә, җиләк-җимеш арзанрак.

2 **ТКХ.** Биш көн һәм аннан да күбрәк өйдә булмаган очракта, ут, су һәм газ өчен түләүне яңадан исәпләтергә дә мөмкин. Моның өчен идарәче компаниягә командировкада яки ялда булуыңны дәлилләп күрсәтергә кирәк. Тик бу техник сәбәпләр аркасында өйдә исәпләгечләр куйдырта алмаган кешеләргә генә кагыла.

3 **Кием-салым.** Җәй – ташламалар чоры. Гадәттә июль урталарында зур сәүдә үзәкләрендә төрле акцияләр, ташламалар башлана. Алардан файдаланып, шактый акчаны янга калдырырга мөмкин.

4 **Ял.** Җәйге ялга акчаны ел дәвамында җыеп барырга киңәш ителә. Болай эшләгәндә, диңгез буена юллама бәясе авыр йөккә әйләнмәячәк. Киләсе ялны никадәр алданрак кайгырта башласаң, ул шул кадәр очсызракка төшәчәк. Мәсәлән, чит илгә юлламаны ел башында 50 процентка кадәр ташлама белән сатып алырга мөмкин.

5 **Транспорт.** Эшегез өйдән бик ерак түгел икән, җәй көне машинада йөргәнче, җәяү әйләнеп кайтырга да була. Акча янчыгына гына түгел, сәламәтлеккә дә бик файдалы булачак.

pixabay.com

ХУШ, КОВИД!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Куркып яшиләр

Питрәч районының Тау Иле авылы фельдшеры Алинә Мөхәмметдинова өчен коронавирус дигән зәхмәт икеләтә зур сынау булган. Ник дигәндә, кызның яшь белгеч буларак авылга кайткан беренче көннәрдә үк диярлек пандемия башлана. Яңа урынга ияләшергә дә өлгерми, моңа кадәр тәҗрибәле табиблар да ни-нәрсә икәнен белмәгән яңа вируска каршы көрәшкә чыгарга туры килә аңа. Авылга кайтканчы башкаладагы бала тудыру йортларының берсендә акушер булып эшләгән яшь белгеч сынатмый үзе. 644 кешелек зур авылга хезмәт күрсәтеп кенә калмый, коронавирус йоктыручыларны да дәваларга керешә.

– Бәхеткә, коронавирус котырган чорда авылыбызда әлеге чирдән бер генә үлемкитем очрагы да булмады. Ләкин күпләр аны авыр уздырды. Аларның күбесе хәзер дә кан басымы уйнаудан тилмерә. Араларында дарусыз тора алмаучылары да, хастаханәдә ятып чыгучылар да бар, – ди Алинә. – Мине иң гаҗәпләндергәне шул: коронавирус кешенең психологик халәтен дә бик нык какшатты. Авылыбызда курку өянәгеннән (панические атаки) интегүчеләр шактый. Алар нерв какшаудан зарлана, тик торганда елап җибәрә, паникага бирелә, гел нәрсәдәндер куркып яши. Алар өчен бер үк вакытта психолог та булырга туры килә. Кулдан килгәнчә тынычландырырга тырышам.

Фельдшер сүзләренә караганда, авылда коронавирус белән авырып сихәтләнүчеләр арасында йөрәк, баш авырту, чәч коелудан зарланучылар да шактый икән. Мәкерле чир котырган чорда өйдән-өйгә йөрү, ковид йоктыручылар белән теләсәң дә, теләмәсәң дә якыннан аралашу Алинәнең үзе өчен дә эзсез калмаган. Үзе дә авырып алган ул.

– Үпкәләремә зыян килде. Аның белән авырганнан соң да бик озак тернәкләндем. Коронавирустан соң үземнең дә кан басымы уйный торганга әйләнде. Элек моның нәрсә икәнен дә белми идем. Хәзер үз сәламәтлегемә игътибарны арттырдым, – ди Алинә Мөхәмметдинова.

Күптән киясе калган

Арча районының Яңа Кенәр участок хастаханәсе педиатры Рәфия Аксакова да, бу чир, иң беренче чиратта, үз-үзеңә игътибарлы булырга өйрәтте дип саный.

Сан

Соңгы өч ел эчендә Россиядә яшәүчеләрнең ярты сыесы диярлек (**48** процент) коронавирус белән авырган. Шуларның **15** процентын бу чир берничә тапкыр аяктан еккан. Россиянең федераль медицина-биология агентлыгы тарафыннан уздырылган тикшеренү нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Тикшеренүдә катнашучылар ковид белән авырганнан соң йөрәк-кан тамыры, сулыш юллары, күз авырулары килеп чыгуын әйткән. Саннар да шуны раслый. Шул ук тикшеренү нәтиҗәләреннән аңлашылганча, пандемия чорында илдә, барыннан да бигрәк, кардиолог (**4,1** процентка), офтальмолог (**3,7** процентка), инфекционист (**1,4** процентка) бусагасын таптаучылар саны арткан.

– Элегрәк шул гади генә битлек киюнең дә әһәмиятен аңлап бетермәгәнбез икән. Вируслы авырулар вакытында битлегең булмаса, ул чир бит инде сиңа да иярә, синең белән гаиләңә дә ияреп кайта. Коронавирус үзебезне дә кайгыртырга, сакларга өйрәтте, – ди тәҗрибәле педиатр. – Кешеләрнең бер-берсенә булган мөнәсәбәтен дә үзгәртте ул. Кешеләр саграк була башлады. Ниндидер бер тәртипкә өйрәнде. Сакланмасам, чир эләгергә мөмкин, дигән уй керде башларына. Шул ук вакцинаны да халык башта мәҗбүр иткәнгә, эштән кушканга гына ясатты. Прививканы бер кат ясаткан кешеләрнең ковид йоктырмавын, авырган очракта да чирне җиңелрәк уздыруын күргәч, халык уянды. Вакцинаны үзе теләп ясатучылар саны артты.

Пандемия чорында Рәфия Аксаковага, нигездә, балалар белән эшләргә туры килгән. Бәхеткә, авылда балалар арасында ковидны авыр кичерүчеләр булмаган. «Авырган балаларда ютәл озакка сузыла. Ул әледән-әле кабатланып тора», – ди белгеч.

Әтнә үзәк район хастаханәсе терапевты Ринат Хәкимҗановка соңгы арада буыннар авыртудан зарланып килүчеләр саны арткан. Ни гаҗәп: алар барысы да диярлек коронавирус белән авырган булган. Хәтер начарлану, начар күрә башлаудан зарланучылар да шактый икән. «Коронавирус аркасында йөрәк тибеше начарланган, үпкәләре зәгыйфьләнеп калган кешеләр шактый. Күп кешедә шикәр авыруы килеп чыкты», – ди табиб.

Ринат Хәкимҗанов – коронавируска каршы беренче көннәрдән үк көрәшкән табибларның берсе. Яңа вирус зур тизлек белән тамыр җәя барган чорда «кызыл зона»да эшләү генә түгел, яшәргә үк туры килә аңа. Тормыш иптәше дә биредә эшли.

– Коронавирус безне, иң беренче чиратта, түзем булырга, бөтен белем-тәҗрибәбезне эшкә җигеп, бербөтен булып эшләргә өйрәтте, – ди табиб. – Халык паникага бирелсә дә, табиблар тынычлык саклады. Хастаханәдә беренче ел гына эшләмибез бит. Мондый катлаулы авыруларга да ярдәм иткән бар. Монда күбрәк вирусның моңарчы күрелмәгән булуы, бик зур тизлек белән таралуы аптырашта калдырды. Башта ул ун кешедә ачыкланса, икенче көнне берьюлы егерме кеше мөрәҗәгать итә иде. Күреп торабыз: чир чигенде. Кешеләр дә тынычлана төште. Шулай да артык иркенәергә кирәкмидер. Һәрхәлдә, коронавируска каршы вакцинаны вакытында ясатып барырга кирәк.

Чәч бәясе

Ике ел дәвамында коронавирус йоктыручылар белән эшләгән Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб-пульмонологы, гастроэнтеролог Рөстәм Насретдинов та шул фикердә. Вирус кеше сәламәтлегенең барлык нечкә урыннарына бәрде, ди ул.

– Коронавирус кичергән кешеләрдә еш кына йөрәк-кан тамырлары чирләре, сулыш алу, неврологиягә бәйле өзлегүләр күзәтелә. Ашказаны-эчәклек, сидек юлы эшчәнлеге белән бәйле проблемалар башланган кешеләр дә шактый. Әмма иң авыры үпкәгә туры килде. Коронавирус белән авырган кешеләрнең күбесенең үпкәсендә әле бүген дә үзгәрешләр күзәтелә. Бронхиаль астмадан интегүчеләр дә шактый, – ди табиб.

Шактый дигәннән, соңгы арада Россиядә чәч күчереп утыртырга теләүчеләр саны арткан. Белгечләр моны һаман да шул коронавирус галәмәте дип бәяли. Казандагы билгеле клиникаларның берсендә эшләүче югары категорияле табиб-трихолог, халыкара трихологлар ассоциациясе әгъзасы Мария Богданова сүзләренә караганда, коронавирус пәйда булу белән, аларга чәч коелудан зарланып килүчеләр саны арткан.

– Ковид вакытында чәчләр кисәк кенә һәм учма-учма булып коела. Бу, иң беренче чиратта, организмның бик зур стресс кичерүенә бәйле. Аннары коронавирус вакытында кан куера бит. Бу исә – организмда кан әйләнеше бозыла, шул исәптән чәч бөртекләре береккән тире катламында да кан дөрес йөрми дигән сүз. Кирәкле матдәләрне җитәрлек күләмдә алмаган чәч коела башлый, билгеле. Ковид вакытында эчкән көчле антибиотиклар да чәч коелуга китерә ала, – ди белгеч.

Мария Богданова сүзләренә караганда, коронавирустан соң чәчләре коелу гына түгел, хәтта пеләшләнүчеләр дә бар икән. Шуңа күрә соңгы арада аларның клиникасында чәч күчереп утырту операциясенә сорау арткан. Ел башыннан бирле аларда чәч үстерергә теләүчеләр саны ике тапкыр диярлек арткан. Алар арасында хатын-кызлар гына түгел, ир-атлар да шактый икән. Сүз уңаеннан, бүген чәч күчереп утырту уртача 100 мең сумнан башлана.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОРОНАВИРУС БЕЗГӘ НИНДИ САБАК БИРДЕ?

Бу сорауны коронавирус чорында РКБда ачылган йогышлы авырулар госпиталендә баш табиб урынбасары вазыйфасын башкарган Сәяр СИРАҖЕТДИНОВка бирдек.

:: Коронавирус безне нәрсәгә өйрәтте?

– Безнең ковид хастаханәсендә коронавирусны катлаулы формада уздырган җитди авырулар дәваланды. Араларында бөтенләй сулый алмаучылар, үпкәләре тулысынча зарарланганнары да шактый иде. Яшәү белән үлем арасының ни дәрәҗәдә якын икәнен дә бик яхшы күрсәтте бу чир. Могҗизалы очраклар да күп булды. Аякка басасына өмет зур булмаган авыруларның да гомерен саклап кала алдык. Гомумән, коронавирус һәркайсыбыз өчен зур сынау булды. Безне – табибларны тиз арада бер йодрыкка берләштереп, гадәттән тыш шартларда эшләргә өйрәтте ул. Баштарак бу мәкерле чирнең нидән гыйбарәт булуы да, аннан нәрсә көтәргә, ничек дәваларга икәнлеге дә билгесез иде бит. Барысына да тиз арада, эшли-эшли өйрәндек. Вирусның дулкын рәвешендә әйләнеп килүе эшне тагын да катлауландырды. Бәхеткә, хәзер ковид тормышыбыздан акрынлап югалып бара. Коронавирус катлаулы инфекцияле авыру булудан туктады. Чирне йоктырган очракта да, ул хәзер гадәти ОРВИ рәвешендә уза.

:: Димәк, хәзер инде тынычланырга була?

– Тынычланырга була дип өздереп әйтмәс идем. Уяулыкны беркайчан да югалтырга ярамый. Шулай да коронавируслы ике ел дәвамында эшләгән вакытлыча госпитальдән кабат үземнең төп эшемә әйләнеп кайтуыма сөенеп туя алмыйм. Тормыш дәвам итә. Травматолог-ортопедларга да эш җитәрлек бүген.

:: Авырган кешеләр хәзер күбрәк нәрсәдән зарлана?

– Ковидның нәтиҗәләре әле дә булса өйрәнелә. Шәхсән үземә килүчеләр арасында кан тамырлары тыгылуга (тромб) бәйле өзлегүләрдән зарланып мөрәҗәгать итүчеләр шактый. Бу, үз чиратында, сәяк тукымасына бик нык зыян сала. Кызганыч, коронавирус белән авырып терелүчеләр арасында сәяк күзәнәге зарарлану (некроз) очраклары да шактый. Ул, нигездә, бот, балтыр, тез тирәсендә очрый. Аларның күбесенә имплант куюдан гыйбарәт булган катлаулы операция ясарга туры килә. Юкса, кеше инвалид калырга мөмкин. Безнең өлкәгә коронавирус китергән иң зур һәм куркыныч зыян әнә шуннан гыйбарәт.

Чир нәрсәгә өйрәтте?

(Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге уздырган сораштыру нәтиҗәләре)

Даими рәвештә тикшерелә башладым – 68 процент
Нинди генә чир белән авырсам да, яңа билгеләргә шундук игътибар итәм – 53 процент
Сәламәтлекнең кадерен белергә өйрәндем – 52 процент
Табиб кушканнарны төгәл үтим – 32 процент
Сәламәт яшәү рәвеше алып барам – 31 процент

students.kpfu.ru

ТОРМЫШ МӘКТӘБЕ

СТУДЕНТЛАРГА КАЙДА ЯШӘҮ ОТЫШЛЫРАК?

Кичәге мәктәп баласына, «Кем булырга?» дигән сорау белән беррәттән, «Кайда яшәргә?» дигәненә дә җавап эзлисе. Кем булсаң да, баш өстендә түбә кирәк. Тулай тораклары, фатирмы? Кайсында яшәү кесәгә дә, күңелгә дә отышлы? «ВТ» хәбәрчесе шуны белеште.

«Кухняны сез җыештырасыз»

– Авыл мәктәбен тәмамлап, КФУга кердем. 1 нче курста Казанныкы булмаган һәр студентка тулай торактан урын бирәләр, миңа да эләкте ул. Киноларда тулай торак тормышын матур итеп сурәтлиләр. Юк, анда тараканнар яшәвен, бар эшне үзеңә башкарырга туры килгәнен болай да беләбез, әмма тулай тораклар эчке «кухня»сын, студентларның аралашуын күрәсем, минем дә шулар урынында буласым килде. Ниһаять, хыялым тормышка ашты: мин Универсиада авылында урнашкан тулай торакка билгеләндем, – дип искә ала кичәге студент Гөлчәчәк Низамиева. – Анда яшәү фатирдан ким түгел дип сөйлиләр иде бит. Беренче бер-ике атнабыз әйбәт узды. Аннары, көнгә әллә ничә тапкыр бүлмәгә кереп тикшерүләр, шәхси комодларны тентү башланды. Өстәвенә кухнябыз 4 бүлмәгә бирелгән иде. Безнең күршеләр рәтендә үзбәк, тажик, урыслар күп, ә татарлар юк иде. Җитмәсә, күбесе – өлкән курс егетләре! Алар бездән көлеп, шаярып көн үткәрә иде, шуңа күрә үзебезнең бүлмәдә ашый башладык, чәйнекне дә бүлмәдә генә кайната идек. Моның өчен безгә әллә ничә тапкыр эләкте инде... Куып чыгарабыз, дип янадылар.

Гөлчәчәк, шундый «вак-төяк»ләр аркасында, тулай торак тормышының ямен күрмәгән. «Өлкән курс егетләре кухняны бары тик без генә җыештырырга тиеш дигән канун да уйлап тапты бер мәлне. Дежурлык дәфтәрендә, тикшерү кергән саен, безнең исем-фамилия тора иде. Без дә – үзсүзле кызлар, кухняда ашаган юк, дип җыештырмадык. Моның өчен тагын эләкте. Тик, бер ачу чыгып, аш-су бүлмәсен җыештырырга дип керсәк, андагы хәлләрне күреп һуштан яздык! Кухня шкафларының ярмалар саклана торган киштәсенә тараканнар оялаган! Бу тараканнарны бүлмәдә дә күргәләдем. Шуңа күрә, өйгә ияреп кайтмагае дип, мин тулай торактан китү яклы булдым. Фатирга кереп торуның мең кат яхшырак икәненә инандым. Баламны да тулай тоакта яшәтмәс идем», – дип искә төшерде студент елларын Гөлчәчәк.

«Начар яшәмәдек»

Журналист белгечлегенә укучы Гөлназ Әхмәдиева исә Универсиада авылындагы шартлардан бик канәгать.

– Шартлар яхшы, бүлмәләр иркен, юыну һәм аш-су бүлмәләре бар, тирә-юньдәге табигать тә матур. Тулай торак кына кешегә мөстәкыйльлек өсти дип уйламыйм, чөнки фатир ни, тулай торак ни – икесендә дә чисталыкны һәм үзеңнең яшәү шартларын карап торырга кирәк, – ди быел 1 нче курсны тәмамлаган кыз. – Беренче чиратта, студентлар өчен тулай торакның кулай ягы – чыгымы аз булудыр. Әгәр тулай тоакта яшәү мөмкинлеге бар икән, аннан файдаланырга кирәк. Биредә бит синең шикелле студентлар, дусларың, бүлмәдәшләрең – алар белән студент тормышы ямьләнә.

Эльвира Ибраһимова моннан берничә ел элек КНИТУ-КАИ бетергән. Студент еллары тулысынча тулай тоакта үткән.

– Укырга кергәндә, тулай торакның, гомумән, укуның нинди буласын видеода күрсәттеләр. Чынбарлыктан нык аерылды инде ул... Әмма мин начар яшәдек дип зарланмыйм, – дип искә ала ул хәзер. – Этажга бер аш-су бүлмәсе иде. Әйе, тараканнар да булды. Коронавирус чорында, өйләргә кайтып киткәч, кайбер студентларның салкын карашы аркасында, тычканнар да ияләште. Суыткычлардан азык-төлекне бушатмаганнар икән.

Елына җиде мең сум түләп торган Эльвира. «Студентларның барысы да тулай тоакта торырга тиеш түгел дип саныйм. Әйтик, «әни малайлары» бар. Үз артларыннан җыештырып йөри белмәгән кешеләр фатирда торса хәерле. Тулай тоактагы бүлмәдә син башкаларның фикерен ишетергә, алар белән санлашырга өйрәнәсең. Башка чараң юк. Районнардан, ераклардан килүчеләргә, тулай тоакта һичшиксез яшәп алырга кирәк! Ияләшү, танышу өчен бик мөһим бу. Авыл балалары баштарак барысын да белеп бетермәскә мөмкин», – дип сөйләде кичәге студент.

Кыйммәтле куыш

Элегрәк, студентка фатирга керергәме, ипотекага алыргамы, дигәндә, милек буенча белгечләр ипотеканы сайларга киңәш итә иде. Янәсе, фатирда да түләп торасың, ә ипотека очрагында, һич югы, үз куышың өчен акча кертәсең. «Лефарт» милек агентлыгы җитәкчесе Ләйсән Гыйлаҗиева сүзләренчә, хәзер вазгыять үзгәргән. Ипотекага караганда, яшь кешегә фатирга кереп тору күпкә отышлырак икән.

– Ипотека ставкасы шактый зур. Бу кешенең кесәсенә суга. Шуңа «снимать» итү ягы кулайрак. Мондый хәлне тарихта беренче тапкыр күзәтәбездер, – ди риелтор. – Арендага килгәндә, студентлар үзәкне һәм Яңа Савин районын үз итә. Икенчесендә сәүдә үзәкләре, парклар күп, шунысы белән алдыра. Транспорт ягы да яхшы. Метросы булган районнарны үз итәләр. Авиатөзәлеш һәм Киров районнарына сорау азрак.

Студентлар еш кына фатир эзләүне август азагына калдыра. Белгеч әйтүенчә, болай эшләргә ярамый, ярык тагарак алдында калырга мөмкинсең. «Сораучылар шактый күбәеп китә, ә тәкъдим аз була. Бәяләр дә күтәрелми тормый. Фатир бәясен генә түгел, торак-коммуналь хезмәтләр һәм башка чыгымнар буласын да истә тотарга кирәк әле», – дип кисәтә Ләйсән Гыйлаҗиева.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Тулай тоакта яшәү

Уку йорты	Бәя (аена)
КФУ	670 сумнан 1250 сумга кадәр
КНИТУ	488 сумнан 1401 сумга кадәр
КНИТУ-КАИ	509 сумнан 591 сумга кадәр
КДМУ	410 сумнан 1367 сумга кадәр
КГЭУ	1 мең сум
КазГИК	958 сумнан 1550 сумга кадәр
КГАСУ	363 сумнан 1252 сумга кадәр
КГАУ	1 мең сум

(уку йортларының рәсми сайтларындагы мәгълүмат нигезендә, бәя студентның нинди шартларда укуына, тулай торакларга бәйле)

Фатирда тору

Казан районы	Бәя (аена, сум)
Вахитов	16–80 мең
Идел буе	11–45 мең
Яңа Савин	14–55 мең
Совет	12–49 мең
Авиатөзәлеш	13–35 мең
Киров	13–40 мең
Мәскәү	12–28 мең



(1 бүлмәле фатир (йә студия), коммуналь хезмәтләрне исәпкә алмыйча, игъланнар сайтындагы мәгълүмат нигезендә)

Фикер

Эдвард ГАБДУЛЛАҖАНОВ, КГЭУ ректоры:

– Тулай тоакта тору яшь кешене тормышка өйрәтә. Кеше социаль мохиттә булырга тиеш. Тулай тораклар-ның да төрлесе була. Әйтик, мин ректор булып килгәннән бирле, без коридорлы тулай тораклардан баш тарттык. Фатир тибында алар безнең. Ялт иткән бүлмәләр! Шартлары искиткеч. Җылы-салкын су бар, студентлар үзләре җыештырмый, бүлмәдәге урын-җирләрне алмаштырып тору каралган. Кер юдырам дисәң, ул хезмәт тә бар. Кыйммәткә түгел, билгеле. Татар халкында шундый сүз бар бит: юкка түзеп була, рәхәткә чыдап булмый. Хәзер менә шунысы белән очрашырга туры килә. Студентка барлык шартлар каралса да, «Ни өчен мин төнгә кадәр йөри алмыйм?» – диярга мөмкин әле ул! Рәхәттән бозылалар *(көлә)*. Әмма эчке кагыйдәләрне үтәргә кирәк. Кеше төнлә йокларга тиеш, көндез – укырга. Без бит ата-аналар алдында җаваплы. Балаларын алар безгә ышанып тапшыра. Төнлә кайда йөри, нишләп йөри, дип борчыла. Бездә тәртип бар.

Беренче-икенче курсларда студент тулай тоакта яшәргә тиеш, дип саныйм. Аннары инде фатир эзләсә дә ярый. Чөнки, үсә төшкән саен, ихтыяҗлары да үзгәрә. Кайсы гаилә кора, кайсы эшли башлый. Миңа тулай торак тормышы эләкмәде. Тормыш мәктәбен электричкада үттем *(көлә)*. Көн-төн электричкага утырып, Биектауга кайтып йөри идем. Тулай тоакта ераклардан килгән иптәшләребез торды. Бер бүлмәдә, ике яруслы караватларда! Берәү дә зарланмады. Яшәргә түбәбез була торып, ничектер тулай тоакта урын сорарга ояла да идек димме. Хәзер якын-тирә райондагылар да урын сорый.

Сан

- Узган елгы кабул итү кампаниясе нәтиҗәләре буенча, Казан вуз һәм ссузларына 158072 студент укырга кергән.
- Казанда читтән килеп укучылар һәм чит ил студентлары өлеше, гадәттәгечә, зур. Әйтик, узган ел, белем алу өчен, Татарстан башкаласына 127 илдән килгәннәр. Аерым алганда, болар – Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кытай, Мисыр, Иран абитуриентлары.
- Хәзерге вакытта Казанда 21 меңгә якын чит ил студенты укый.

10 июль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
07.05, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». Телесериал 16+
13.00 «Ком сәгате» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Гаилә учагы» 16+
00.00 «Соотечественники». Борис Железнов. Из меня растут стихи 16+
00.25 «Каравай» 6+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Сәгыйть Хәбибуллин турында телеочерк 16+
07.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
07.15, 12.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телевизион нәфис фильм 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 Ш.Хөсәенов. «БЕЗНЕҢ ПОДЪЕЗД ТӨБЕ». Телеспектакль 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Янар чәчәк». Мирсәет Яруллин турында телеочерк 16+
14.00 «Муса батыр очкан чакта...» Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәев турында телеочерк 16+
15.30, 03.15 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Сәгыйть Хәбибуллин турында телеочерк 16+
17.30 «Яшьләр туктalышы» 6+
19.10, 22.15, 03.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 М.Гыйләҗев. «БАСКЕТБОЛИСТ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+

1 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Милош Бикович в многосерийном фильме «МАГОМАЕВ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+

1 РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «СОФИЯ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Премьера. «СЫН» 16+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.55 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ! МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный интерес» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 09.40, 12.55, 14.55, 17.00, 18.55, 20.55 Новости
07.05, 20.20, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.45 Автоспорт. Ралли-рейд «Шёлковый путь» 0+
10.05 «Кубок PARI Премьер». Специальный репортаж 12+
10.25 Футбол. Кубок PARI Премьер. «Нефтчи» (Азербайджан) – «Црвена Звезда» (Сербия). Трансляция из Санкт-Петербурга 0+
12.35, 23.40 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00, 03.00 «Кто кого?» 12+
15.30, 17.05 «РЕАЛЬНЫЙ РОККИ» 16+
17.30 «Громко». Прямой эфир
19.00 Смешанные единоборства. UFC. Ронда Роузи против Холли Холм. Трансляция из Австралии 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.00 «Лошадиная сила». Документальный сериал 12+
01.20 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 4. Трансляция из Москвы 0+
02.55 Новости 0+
03.30 Академическая гребля. Кубок мира. Трансляция из Швейцарии 0+
04.45 Пляжный футбол. OLIMPBET Чемпионат России. Женщины. 1/2 финала 0+

НТВ

05.15 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
07.00 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие». 14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Александр Устюгов в детективе «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.25 «Основано на реальных событиях» 16+
01.20 Дмитрий Певцов в боевике «ВНУТРЕННЕЕ РАССЛЕДОВАНИЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.50 «Давай разведёмся!» 16+
08.50 «Тест на отцовство» 16+
11.05 «Понять. Простить» 16+
12.20 «Порча». «Ошибки прошлого» 16+
12.50 «Знахарка» 16+
13.25 «Верну любимого» 16+
14.00 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «Преступления страсти» 16+
19.00 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
22.45 «Понять. Простить» 16+
00.00 «Порча» 16+
00.25 «Знахарка» 16+
00.50 «Верну любимого» 16+
01.20 «Голоса ушедших душ» 16+
01.45 «ВТОРАЯ ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+

ЗВЕЗДА

04.40 «НЕВЫПОЛНИМОЕ ЗАДАНИЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00 «ДВА КАПИТАНА». Телесериал. «Старые письма» 12+
12.30, 13.25 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.» Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
17.05 «Освобождение Европы». Документальный сериал. «От Буга до Одера» 16+
18.00 «Освобождение Европы». Документальный сериал. «Пражский прорыв» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Загадки века». Документальный сериал. «СССР. Урановый проект» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДВОЙНОЙ ОБГОН» 16+
01.00 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ». Телесериал. 1-я – 3-я серии 16+
03.15 «Выдающиеся авиаконструкторы». Документальный сериал. Семен Лавочкин 16+
03.50 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.» Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

11 июль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
07.05, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». Телесериал 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Гаилә учагы» 16+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Особенности вкуса русской традиционной кухни 6+
00.50 «Соотечественники». Айрат Арсланов. Мастер художественного слова 16+
01.15 «КВН РТ-2022» 12+
02.05 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Әнвәр Бакиров турында телеочерк 16+
07.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
07.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». Телевизион нәфис фильм 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.30 «Насыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
13.45 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Әнвәр Бакиров турында телеочерк 16+
15.30, 03.15 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.15, 22.15, 03.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
01.05 Н.Гыйматдинова. «БҮРЕ КАНЫ». Тубән Кама Татар дәүләт драма театры спектакле 16+

1 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «МАГОМАЕВ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Эйзенштейн 125» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Эйзенштейн 125» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+

1 РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «СОФИЯ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «СЫН» 16+
23.15 «Вечер» 12+
02.05 «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.55 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ! МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный интерес» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 09.40, 12.55, 14.55, 17.00, 18.55, 20.55 Новости
07.05, 15.30, 20.20, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.45 Автоспорт. Ралли-рейд «Шёлковый путь» 0+
10.05, 12.35, 23.40 Специальный репортаж 12+
10.25 Футбол. Кубок PARI Премьер. «Зенит» (Россия) – «Фенербахче» (Турция). Трансляция из Санкт-Петербурга 0+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00, 03.00 «Кто кого?» 12+
16.30 «География спорта. Нижний Новгород» 12+
17.05 «Чемпионы». Документальный фильм 12+
19.00 Смешанные единоборства. UFC. Джулианна Пенья против Аманды Нуньес. Трансляция из США 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.00 «Лошадиная сила». Документальный сериал 12+
01.20 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 4. Трансляция из Москвы 0+
02.55 Новости 0+

НТВ

05.15 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
07.00 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие» 14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Детектив «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.25 «Основано на реальных событиях» 16+
01.20 Боевик «ВНУТРЕННЕЕ РАССЛЕДОВАНИЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Стрелки назад» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «СЛЕДУЯ ЗА СЕРДЦЕМ» 16+
22.45 «Понять. Простить» 16+
00.00 «Порча» 16+
00.25 «Знахарка» 16+
00.50 «Верну любимого» 16+
01.20 «Голоса ушедших душ» 16+
01.45 «СЕЗОН ЛЮБВИ» 16+
05.05 «Преступления страсти» 16+
05.55 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.» Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ДВА КАПИТАНА» Телесериал. «ТАТАРИНОВЫ» 12+
12.30, 13.25 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.» Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
17.05 «Освобождение Европы». Документальный сериал. «Венская наступательная операция» 16+
18.00 «Освобождение Европы». Документальный сериал. «Огненный штурм Буда и Пешта» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Битва за эфир. Как средства РЭБ стали идеальным оружием» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДВА ДОЛГИХ ГУДКА В ТУМАНЕ» 12+
01.00 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ». Телесериал. 4-я – 6-я серии 16+
03.10 «Выдающиеся авиаконструкторы». Документальный сериал. Олег Антонов 16+

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
6 июль, 2023 ел, № 19/134 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Сарман районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Сарман районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләренең туктатылуына бәйле рәвештә, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Сарман районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләү өчен, кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул итү турында белдерә.

Документлар 2023 елның 7 июленнән 20 июленә кадәр эш көннәрендә 9.00–18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7 б й. (элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Территориаль, округ һәм участок сайлау комиссияләрен булдыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 15 март, 2023 ел, № 111/863-8 Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
6 июль, 2023 ел, № 19/135 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Кайбыч районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Кайбыч районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләренең туктатылуына бәйле рәвештә, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Кайбыч районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләү өчен, кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул итү турында белдерә.

Документлар 2023 елның 7 июленнән 20 июленә кадәр эш көннәрендә 9.00–18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7 б й. (элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Территориаль, округ һәм участок сайлау комиссияләрен булдыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 15 март, 2023 ел, № 111/863-8 Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ШИФА – АЯК АСТЫНДА

Күбебез теге яки бу чирдән шифаны дарудан түгел, дару үләннәреннән таба. Шуңа учлап-учлап төймә ашарга күнеккән күпләрнең соңгы арада тузганактан кышка кайнатма әзерләп, аяк астында гына үсеп утырган файдалы үләннәрне киптереп куярга тырышуына аптырый торган түгел. Әмма дару үләннәрен дә белеп кенә җыярга кирәк. Юкса аларның да дарудан бигрәк агуга әйләнүе бар.

40 елдан артык дару үләннәре җыючы Фирая ЗАХАРОВА бу җаваплы эшнең нечкәлек-серләрен укучыларыбызга да җиткерде.

✓ Дару үләне кешегә ярдәм итәргә дә, зыян салырга да мөмкин. Алар артык батырланганны яратмый. Шуңа күрә махсус белемең булмаган килеш бу эшкә бөтенләй тотынмавың хәерле.

✓ Хәзер кайбер дару үләннәрен җыеп өлгерергә кирәк.

• Каен яфрагы, бака яфрагы (подорожник), әрем, шомырт җыяр чак. Алар ел әйләнәсе кулланыла. Бик күп инфекцияле, вируслы авырулар вакытында ярдәмгә килә.

• Июльдә кычыткан, әрем, шомырт, алмагач яфракларын җыярга кирәк. Әрекмән яфраклары җыярга да онытмагыз. Аннан сок чыгарырга мөмкин. Бераз шикәр кушсаң да була. Бу сокны суыткычта саклыйсы. Әлеге үсемлекнең яфрагы гына түгел, тигәнәгенә кадәр файдалы. Бишалты тигәнәкне бер стакан суга салып төнәтеп, чәй итеп эчкән кешегә ютәлдән башлап яман шешкә кадәр булган катлаулы чирләр янамаячак.

• Бака яфрагы үләнен шул килеш кенә ашарга да, салатларга кушарга да була, согын чыгарсаң да ярый. Ул ашказаны согының кислоталылыгы артык югары булган кешеләргә, ашказаны җәрәхәтеннән интегүчеләргә файдалы.

vk.com

• Тал кайрысы да җыеп куярга киңәш ителә. Анысы канны сыеклата. Укроп, бөтнек, бака яфрагы, азрак гөлҗимеш салып, чәй ясап эчсәң дә бик файдалы. Әмма мондый чәйне эчәр алдыннан аны башта авыз итеп карап, организмның реакциясен тикшерергә кирәк.

✓ Дару үләннәреннән төнәтмә һәр кешегә организмының үзенчәлекләрен истә тотып ясалырга тиеш. Дару үләннәре белән дәваланыр алдыннан иң элек кан басымын, кандагы шикәр күләмен, ашказаны эшчәнлеген тикшертү, анализлар тапшыру, УЗИ ясату зарур.

✓ Йөкле хатыннарга, 5 яше тулмаган кечкенә балаларга үләннәр белән дәвалырга ярамый. Хроник чирләре булган кешеләргә дә сак булырга кирәк.

✓ Дару үләннәрен явым-төшемсез, коры көндә, иртәнге якта җыйсаң яхшы. Яңгырдан соң җыелган үлән тиз күгәрә, аның файдасы калмый. Составында эфир майлары булган үләннәрне эссе, кояшлы көндә җыярга кирәк. Җиләкләрне иртән иртүк, йә булмаса, кичен җыйсаң яхшы. Озак сакланачак дару үләнен кайчы белән кисеп җыярга кирәк.

✓ Иммунитетны бер көндә генә, нинди дә үлән ярдәмендә генә ныгытып булмый. Организм төрле вирус-инфекцияләргә каршы торуга алдан әзерләнергә тиеш. Иммунитет нык булсын өчен, иң беренче чиратта кешенең ашказаны-эчәк системасы яхшы эшләргә тиеш. Моның өчен парда пешерелгән ризыкка өстенлек бирү зарур. Кипкән җимешләрдән компот, морс, кесәл кебек эчемлекләрне дә күбрәк кулланырга кирәк. Арыслан койрыгы (пустырник), бөтнек, песи үләне, эт тигәнәге (череда), сары мәтрүшкә бик яхшы тынычландыру үзлегенә ия. Нерв системасы аерым бер «хуҗалык» булып яшәми бит. Аның дөрес эшләве бөер, бавырның көйле эшләвенә дә бәйле. Каен яфрагы, гөлҗимеш бөерләргә файдалы булса, меңьяфрак, сары мәтрүшкә, ромашка бавырга шифалы.

✓ Гөмбәләр кебек үк, дару үләннәре арасында да бер-берсенә охшаш үсемлекләр күп. Әйтик, түндербашны балтырган белән бутап була. Икесенең дә чәчәкләре чатыр рәвешендә. Шуңа күрә таныш булмаган үләннәрне бөтенләй читләп үтәргә киңәш итәм. Теге яки бу үлән шик уятса, белгеч белән киңәшләшү хәерле.

✓ Хәзер каен, җир, бакча җиләкләре өлгергән чак. Аларның җимеше генә түгел, яфрагы да файдалы. Алар үпкә, бөер авыруларын җиңәргә ярдәм итә. Вирус, микробларга каршы, бәвел кудыру өчен дә бик яхшы чара бу. Шушы чорда өч литр чамасы каен җиләге ашап өлгерсәгез, иммунитетыгыз ел дәвамында сынатмас. Кура җиләгендә дә организм өчен кирәкле бөтен файдалы матдәләр бар.

✓ Үләннәрне җыю чорын вакыт ягыннан чикләп карау дөрес түгел. Питраудан соң күп кенә дару үләннәре файдалы үзлекләрен югалта, дигән фикер белән дә килешмим. Мисал өчен, Арча районында балан Казандагыга караганда ун көнгә соңрак чәчәк ата. Шуңа күрә дару үләннәрен үсеше, өлгергәнлек дәрәҗәсенә карап җыярга кирәк.

ДАРУ ҮЛӘННӘРЕН НИЧЕК КИПТЕРЕРГӘ?

1. Кибәргә куелган үләннәрне кояшта тотарга ярамый. Аны бераз үтәли җилле урында, саф һавада киптерергә кирәк. Үлән киптерү өчен иң яхшы урын – чорма.
2. Ромашка, мәтрүшкәләрне, каен яфрагын бәйләм итеп җыеп элеп киптерсәң яхшы.
3. Үлән тамырлары кояшта яхшы кибә.
4. Бака яфрагы белән үги ана яфрагын кәгазьгә берәмләп куеп киптерергә кирәк. Өсте-өстенә салынса, алар кибә алмый, каралып чери башлаячак. Берике көннән аны икенче ягын әйләндереп тә киптерәсе була.
5. Һәр төр үләнне аерым киптерергә кирәк. Киптергәч, аның кайсы үлән икәнлеген, кайчан җыелганлыгын язып куярга да онытмагыз.
6. Кипкән үлән озаклап тузан җыеп ятарга да тиеш түгел. Шуңа күрә аны кибүгә үк урнаштырырга кирәк.

Фирая Захаровадан витаминлы чәй рецептлары

Күпьеллык тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: аерым бер үләнне генә файдаланугa караганда, берничә үләнне берьюлы куллану нәтиҗәлерәк. Дару үләннәреннән төнәтмәләр һәркем өчен аерым ясалса да, шифалы үләннәрдән торган витаминлы чәйне барыбыз да ясый ала. Иң элек бераз гөлҗимеш, дүләнә (боярышник), укроп, бөтнек, бака яфрагы, ромашка яфракларын ваклап, шуларга бераз тал кайрысы салып, чәй кебек кайнатып эчәргә мөмкин. Күрәгә, өрек, финик, инжир, йөземгә бераз гөлҗимеш салып, лимон һәм дарчин өстәп кайнатылган чәйнең дә шифасы әйтеп бетергесез. Бер ясалган чәйгә кайнар су өсти-өсти, өч көн эчәргә мөмкин.

Табигать даруханәсе

ГИПЕРТОНИЯДӘН – КӨНБАГЫШ

Бик күп төрле витаминнар чыганагы булган көнбагыш орлыгы төнәтмәсе кан басымын төшерә. Аны ясау өчен 500 г чистартылмаган, кыздырылмаган көнбагышны яхшылап юарга һәм 0,5 л салкын суга салып, сүрән утта 1,5–2 сәгать кайнатырга кирәк. Алга таба шуны сөзеп, суытасы булачак. Шушы төнәтмәне иртән һәм кич яртышар стакан эчәргә кирәк. Әлеге төнәтмә ярдәмендә 2 атна дәвалангач, 5 көн тәнәфестән соң курсны тагын бер тапкыр кабатларга мөмкин. Әмма шунысын да исегездән чыгармагыз: һәр иртәне яңа төнәтмә әзерләргә кирәк.

ЭЧ КИТҮДӘН – ШОМЫРТ

100 грамм киптерелгән шомыртка 250 мл су салып, 15 минут кайнатабыз. Соңрак шуны уттан алып, суынырга куябыз. Бу төнәтмәне көненә ике тапкыр бер стакан күләмендә эчәргә кирәк.

Киңәш-табыш

Кайсы ит файдалырак?

Тавык ите. Анда А, В, Е витаминнары, фосфор, тимер, калий, магний күп. Аны өлкәннәргә дә, балаларга да ашарга ярый. Ул канда шикәр микъдарын көйли, йөрәк эшчәнлегенә уңай йогынты ясый. Тавыкның бердәнбер кимчелеге – аның тиресе бар, ә тавык тиресендә холестерин күп була.

Күркә ите. Ул иң диетик ит санала. Анда май күләме иң азы, тик күркә ите авыр үзләштерелә. Анда минераллар һәм витаминнар күп, күркә ите кан составын яхшырта.

Сарык ите. Витаминнарга бай, анемиядән саклый, сыер итенә караганда холестерин азрак. Диабетны кисәтүче ризык санала.

Сыер ите. Сыер ите организмның саклагыч функциясен көчәйтә. Кан тамырларын яхшырта, ашкайнату эшчәнлеге өчен файдалы.

Ат ите. Сыйфатлы аксымга бай, сыер итенә караганда җиңелрәк үзләштерелә. Диетик ризык булып санала.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

САК БУЛ, АТМАСЫН!

Бу көннәрдә хуҗабикәләрнең аш бүлмәләрендә эш кайный. Узган елгыга караганда яшелчә, җиләк-җимеш уңышы аз булганлыктан, ул аеруча кадерле. «Булганы җитәр», – дип, үзебезне тынычландырсак та, әзерләнгән нигъмәтләрнең кышка кадәр саклануы мөһим. Әчемәсен, капкачлары атмасын, тозлык болганчыкланмасын өчен, кайбер киңәшләрне исегезгә төшерергә, хаталарны барларга булдык.

1 Кышка әзерләнә торган яшелчә, җиләк-җимешләрнең «сәламәт» булуы мөһим. Бу инде – бәрелмәгән, изелмәгән, төсен җуймаган, чери башламаган булырга тиеш дигән сүз. Гадәттә, хуҗабикәләр кыяр берничә көн торганнан соң, помидорлар бераз йомшарып, чери башлаган урыннарын кисеп атып, «салатка ярый» дип кулланалар, яисә бу эшне муллык чорына – көзгә калдыралар. Әменә яңа өлгергән, яңа өзелгән кыяр-помидор, җиләкләрдән кышка әзерләгән ризык тәмлерәк тә булачак, озаграк та сакланачак.

2 Тозлау, салатлар ясау өчен эре тоз кулланырга кирәк. Сатып алганда тозның кабына игътибар итегез: «Помол №1» дип язылган булса яхшы. Вак экстра тозы кыярны йомшартырга, йодлысы яшелчәләрнең тәмен һәм төсен үзгәртергә мөмкин.

3 Тозлау өчен суның сыйфаты да мөһим. Тозлык ясаганда һәм яшелчәләрне суга салып тоткан да, чишмә, кое суы яки яхшылап фильтрланганны куллансаң яхшы. Шәһәр җирендә, хлор тәме калмасын өчен, фильтр аша үткәрү бигрәк тә кирәк. Иң мөһиме: су озак торган, алдан җыеп куелган булмасын, шулай ук яхшылап кайнатып чыгарырга иренмәгез.

4 Тозлаганда, салат һәм кайнатма ясаганда тоз, шикәр комы, аш серкәсе һәм лимон кислотасын чама белән салырга ярамый! Берсен азрак, икенчесен күбрәк куллану да файдага түгел. Рецептта күпме диелгән, шулкадәр салырга кирәк. Әгәр үзегезне бик тәҗрибәле «банка ябучы» дип санамасагыз, әни, әби яки башка танышларыгызның сынап караган рецептларын кулланыгыз.

vk.com

5 Әгәр сез эре яшелчәләр кулланасыз икән, аларга тоз начаррак сеңә, бераздан тозлыгы болганчыкланырга мөмкин. Шуңа күрә эре яшелчәләр кулланганда, тозын бераз артыграк салырга киңәш ителә.

6 Гап-гади гигиена таләпләре турында онытмау хәерле. Яшелчә, җиләк-җимеш, банкалар тиешенчә юылган, чистартылган булганда гына кышка кадәр сакланырга мөмкин. Банкаларны стерильләштерү дә – уңышның яртысы. Сода белән сабынлы суда яхшылап, шыгырдап торырлык итеп юылган банкаларны духовкада, микродулкынлы мичтә, пар ваннасында тотарга яки кайнаган су белән пешекләп алырга була. Үзегез өчен уңайлысын сайлыйсыз.

7 Банкаларга тутырылган нигъмәтләрне стериль тимер капкачлар белән каплаганнан соң, аны әйләндереп куярга, ягъни капкачына бастырырга кирәк. Бу банка капкачы кырыендагы силикон бөжра йомшарып, банка авызына тагын да ныграк берексен өчен шулай эшләнә. Банкаларны кимендә 1–2 сәгать шулай баштүбән тотарга, өстенә калын әйбер ябарга, суынгач кына алырга киңәш ителә.

Белеп тор!

ТӘЛИНКӘ АГАРТАБЫЗ

1. Озак кулланганнан соң тәлинкәләрнең тышы саргаеп китә. Чистарту өчен аны кайнап чыккан суга салып, 10 минут тотыгыз. Суын түккәч, таплы җирләренә сода сибеп чыгыгыз, аннары өстенә серкә салыгыз. Күбекләнүдән туктагач, тәлинкә тышын губка белән ышкыгыз. Саргайган урыннарның эзе дә калмаячак.

2. Табакка кайнар су, 30–50 г кер порошогы һәм шул ук күләмдә коры агарткыч (отбеливатель) салып болгатыгыз. 2–3 сәгатькә тәлинкәләрне шуңа салып тотыгыз һәм гадәттәгечә юып алыгыз, яхшылап чайкагыз. Савыт-саба юа торган машинада юган төсле ялт итеп торачак.

Исеңдә тот!

Кавын сайлау

Кавынны ике кулыгыз белән тотып, акрын гына кысып карагыз. Яхшы, өлгергән кавын гандбол тубы кебек, пружина сыман «уйнап» торырга тиеш. Әгәр дә ул кысып караганда карбыз сыман каты икән, димәк, әле өлгермәгән дигән сүз. Кысканда бармак эзләре кала икән, артык өлгергәнлеген, куллану вакыты чыгып килүен аңлата.

«Колхозница» сортының тышы шома, ә «Торпедо»ныкы кытыршы, сырлы була. Җитешкән кавынның кабыгын акрын гына кырып карасагыз була. Өлгергәненең кабыгы бик җиңел кырыла, ә өлгермәгән булса, шома булып тора, кырылмый.

Бакчачыга

Чәчәкләр патшабикәсе – розаны яратмаган кеше юктыр. Ә менә аны үстерә белүчеләр яратучылар кадәр үк түгел. Розага караганда әллә ни тәрбия таләп итмәгән, ә аңа охшаган гөлләрне утыртып та була бит. Алар тәрбиягә нәзберек түгел, мәшәкате азрак санала.

Эустома

Йөнтәс бальзамин

Камелия

Бегония

Ранункулюс

Кышка әзерлек

КАРА КАРЛЫГАННАН КАЙНАТМА

Сания ЗЫЯТДИНОВА рецепты

2 стакан суга 8 стакан шикәр комын әз-әзләп салып җебетәсең.

Чистарткан, юган 8 стакан карлыганны шушы сироп өстенә салып, кайнап чыкканнан соң 15 минут кайнатып сүндерәсең (күбеген җыйганым юк).

Яңадан 8 стакан шикәр комын шуның өстенә салып, эреп беткәнче болгатасың.

Тәмле вареньены юылган, коры банкаларга кайнар килеш тутырып куясың.

ТОМАТЛЫ КЫЯР САЛАТЫ

Илсинә ЯРУЛЛИНА рецепты

5 кг кыярны ярымбожралап турыйбыз. 0,5 литр томат пастасы, 100 г аш серкәсе, 200 г шикәр комы, 2 аш кашыгы тоз, 200 г сыек май салып болгатабыз һәм утка утыртабыз. Кайнап чыккач, сүрән утта 10 минут пешерәбез. Кайнар килеш стериль банкаларга тутырабыз. Җиде 1 литрлы һәм 750 граммлы бер банка чыга. Бик тиз һәм җайлы эшләнә, бик тәмле дә.

Укучы киңәше

Кабыгы файдалы

Мин мандарин кабыгын җыеп барам. Аны киптереп, пыяла савытларда саклыйм. Аннан гөлләрне һәм чәчәкләрне корткычлардан саклый торган төнәтмә ясарга була. Мандарин кабыгына 1:2 исәбеннән кайнап торган су салып, бер тәүлек караңгы урында төнәтәбез. Икенче көнне аны сөзеп, 1:2 исәбеннән чиста су кушып, гөл яфракларының ике ягына да пульверизатор белән сиптерәбез. Әлеге төнәтмә төрле корткычлардан саклый. Шулай ук төбенә ашлама итеп тә сибәргә була.

А. СӘЛИМОВА. Арча

КҮЗ ДӘ, ЙӨРӘК ТӘ – АЛЛАҺНЫКЫ



dumrt.ru

Үлем белән картлыктан гына дәва юк. Аңа кадәр сәламәтлегебезне кайгырту әманәт булып тора. Изге китапта: «Кеше башка берәүне дәваласа, аның гомерен саклап калса, бөтен кешелекне терелткән кебек булыр», – диелә. Мохтаҗ булган кешегә кан бирү, әгъзаңны сату игелекле эш саналамы? Гомумән, ислам дине әлеге күренешләргә нинди карашта? Бу – гөнаһмы, әллә хуплана торган гамәлме? Кызыксындырган сорауларыбызга Раил хәзрәт ФӘЙЗРАХМАНОВ ачыклык кертте.

:: Кеше әгъзаларын күчереп утыртуга дин нинди карашта? Бу рөхсәт ителәме?

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Әссәламәгаләйкүм вә рәхмәтуллаһү вә бәрәкәтүһ! Бу җәһәттән дин галимнәренең фикерләре аерыла. Беренчеләре, гомумән, ярамый, ди. Чөнки тән әгъзалары – Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә бирелгән нигъмәт. Без алар белән теләгәнчә идарә итә алмыйбыз. Икенче галимнәр ярамый дип тә, ярый дип тә әйтми. Өченчеләр, ярый, ди, әмма шарт куя. Әйтик, кеше исән чагында берәр әгъзасын танышына, туганына бирергә тели икән, моңа өстәп, бу эше белән организмына зыян салмаса, ярдәм, сәдака ниятеннән бирә икән, бу рөхсәт ителә. Үзенә зыян салырлык итеп эшләнсә, тыела.

:: Үз әгъзаларыңны акча эшләү максатыннан сату – гөнаһмы? Сер түгел, чәч, мәни сатып акча эшләүчеләр бар бит.

– Дин галимнәре әгъзаларны сатып акча эшләүне тыя. Әгәр дә бер кешедән икенче кешегә әгъзалар күчереп утыртасы булса, ул бүләк йөзеннән, изге нияттән генә эшләнергә тиеш. Күзләр, бөерләр, аяклар, куллар һәм башкасы – безнеке түгел. Ул – Аллаһы Тәгаләнеке.

:: Кан бирү күренешенә карата дин нинди фикердә?

– Кан бирү рөхсәт ителә. Әйткәнебезчә, кеше үз организмына зыян китермәгән очракта. Бу да акчага эшләнергә тиеш түгел. Сатарга ният булмыйча, әмма соңрак кан биргән яисә әгъза күчереп утырткан кешенең якыннары килеп, бу кешегә бүләкме, акчамы бирсә, зыяны юк. Әмма башта ук фәлән сум акча эшлим дигән шарт куелырга тиеш түгел.

:: Үз әгъзаларыңны васыять итеп калдырырга ярыймы соң? Күпләр фән өчен, башка кешеләр сәламәтлеге өчен дип, шулай итә бит.

– Васыять итеп калдырсаң, ярый.

:: Мөселманга башка дин кешесенең әгъзасын күчереп утырту – гөнаһмы?

– Әлбәттә, иң хәерлесе – мөселманга мөселман кешенең әгъзасын күчереп утырту. Әмма төрле хәлләр була, гомерне саклап калу, сәламәтлекне яхшырту өчен, галимнәр башка диндәге кешеләрнең дә әгъзаларын алырга рөхсәт итә.

Белеп тор!

Нәрсә ул гөнаһ?

Гөнаһ ул – кешенең ахирәттә газаплануына сәбәп булачак сүзләре, эшләре һәм хәрәкәтләре. Ислам динендә гөнаһлар ике төрлегә аерыла.

Беренчесе «гөнаһи кәбаир» (зур гөнаһлар) дип атала, икенчесенә «гөнаһи сәгаир» (кечкенә гөнаһлар) диелә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

> «Әгәр сез Аллаһы тарафыннан тыелган гөнаһларның зурларыннан саклансагыз, сездән кечкенә гөнаһларны да ерагайтырбыз һәм сезне шәрәфле бер урынга күтәрербез».

Аллаһы Тәгалә кемнедер яки нәрсәнедер Үзенә тиң күрүдән башка бөтен гөнаһларны гафу итә ала. Әлбәттә, бу «барлык гөнаһлар да һичшиксез гафу ителер» дигән сүз түгел: һәр аерым очракта Аллаһы Тәгалә – Үзе хөкем кылучы. Аллаһы Тәгалә кешеләрнең гөнаһ эшләвен теләми. Кеше гөнаһ эшләгән булса, Ул аннан тәүбә көтәр. Әгәр кол, Аллаһыга ялварып, эшләгәннәреңә үкенеп, киләчәктә ул хатаны эшләмәскә вәгъдә бирсә, Аллаһы каршында тәүбә итсә, иншә Аллаһ, Җәнаби Хак Раббыбыз бу колын гафу итәр.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә шулай дигән:

> «Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы [ширектән тыш] барлык гөнаһларны да ярлыкый!» һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».

(«Ислам дине нигезләре» китабыннан)

Йәгез, бер дога!

КҮК КҮКРӘГӘНДӘ УКЫЛА
Сүбхәнәлләзи йүсәббихүр-рагьдү бихәмдиһи үәл-мәләʻикәтү мин хыйфәтиһ.
Мәгънәсе: «Күкрәү һәм фәрештәләр, Аннан куркып, мактау тәсбихләре әйткән Аллаһ һәр кимчелектән пакь!»

ЯҢГЫР ЯУГАЧ УКЫЛА
Мүтыйрнә бифәдълилләһи үә рахмәтиһ.
Мәгънәсе: «Аллаһның фазыйләте вә рәхмәте илә безгә яңгыр яуды».

ЯҢГЫР СОРАГАНДА УКЫЛА
Аллаһүммәскый гыйбәдәкә үә бәһәʻимәкә үәншүр рахмәтәкә үә әхйи бәләдәкәл-мәйит.
Мәгънәсе: «Әй Аллаһ! Үзеңнең колларыңны, хайваннарыңны сугар. Үзеңнең рәхмәтеңне җәй һәм мәет булган җиреңне терелт!»

ЯҢГЫР ЯУГАНДА УКЫЛА
Аллаһүммә сайибән нәфиган.
Мәгънәсе: «Әй Аллаһ! Бу яңгыр файда китерсен!»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гыйбрәт ал!



vk.com

«Сиңа су кирәкме?»

Әбү Җөһәйм бине Хозәйфә радыяллаһү ганһе болай дип сөйләгән:

– Ярмүк сугышы вакытында мин яралылар арасында абыемның улын эзләдем. Минем бераз суым бар иде һәм мин үземә: «Әгәр аны исән көе тапсам, аңа су бирәп, йөзен сөртер идем», – дидем. Бу вакытта көтелмәгәндә мин аны үз янымда күрдем. Мин аннан: «Сиңа су бирергәме?» – дип сорадым. Ул «әйе» дигәнне белдереп, башын какты. Бу вакытта тагын берәүнең ыңгырышкан тавышы ишетелде. Абыемның улы миңа башын селкеп, аңа су бирергә кушты. Бу кеше Хишам бине Гас иде. Мин аннан: «Сиңа су бирергәме?» – дип сорадым. Бу вакытта тагын кемнеңдер ыңгырашуы ишетелде. Хишам миңа, суны аңа илтүемне сорап, башын какты. Мин суны илтә киттем, әмма аның янына килеп җиткәндә, бу кеше үлгән иде. Мин Хишам янына кайттым, әмма ул да үле иде инде. Шуннан соң мин абыемның улы янына юнәлдем, ул инде вафат иде.

Башкаларны үзеңнән өстенрәк күрү турында бу. Әлеге хикәятнең нәсыйхәте Коръәни Кәримдә дә язылган:

«Үзләрендә ихтыяҗ булса да, [ашамыйча-аша-тып, киенмичә-киендереп] аларны үзләреннән өстен күрәләр».

(«Әл-Хәшр / Җыен», 59:9)

(«Рухуль-Бәйан» китабыннан)

Төрлесеннән

Җаваплар Рамил хәзрәт ЮНЫСның социаль челтәрдәге сәхифәсеннән алынды.

?Җан тынычлыгын ничек табарга? Күңел эзләнә, ашкына...

– Урманны яратам, дип әйтү генә аз булыр, – ди Гөлнур Сәлимгәрәева. – Ялгызым гына да барырга курыкмыйм, инде ничә еллар йөреп, һәр сукмагын өйрәнеп бетердем. Көн саен яки көнаралаш барам бит. Июнь урталарында ике көн бәрәңге чүбе утадык, төбен өйдек. Шул көннәрдә урманга бара алмаганга йөрәгем әрнеде инде. Урман бай ул, тик һәр нәрсәне вакытында җыеп алырга кирәк. Бай гына түгел, серле һәм рәхмәтле дә ул.

Гөлнур Сәлимгәрәева рецептлары

КАТЫРЫЛГАН АК ГӨМБӘДӘН АШ

Катырылган ак гөмбә тавык шулпасы өчен бик тәмле. Иң элек йорт тавыгыннан шулпа кайнатасың. Итен алгач, шулпага туралган ак гөмбә саласың, ул бераз гына пешкәч, өй токмачы саласың. Токмач күтәрелеп чыгуга ук, тавык итен ваклап, шулпага салып җибәрәсең дә 5 минут тирәсе кайнатасың. Ресторан ризыкларыннан бер дә ким булмаган аш әзер!

САРЫМСАК УГЫННАН СОУСЛАР

Сарымсак угын блендерда ваклап, шуңа тоз, кара борыч, көнбагыш мае, кипкән тәмләткечләр салып болгатасың. 15–20 минут тоткаңнан соң контейнерларга тутырып куясың. Икенче ысулы да бар: сарымсак угын шулай ук блендерда изеп, көнбагыш мае, тоз, кара борыч, чабыр үләне салып болгатасың.

УТЛЫ ДУГА

ТАРИХ БИТЛӘРЕНӘ КУРСК ДУГАСЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН КЕРЕП КАЛГАН, СУГЫШ БАРЫШЫН ТАМЫРДАН ҮЗГӘРТКӘН БУ ВАКЫЙГАГА – 80 ЕЛ

Курск сугышы – дөнья тарихында танк дивизияләре катнашында барган иң зур бәрелешләрнең берсе. Ул 1943 елның 5 июлендә башланып, 23 августка кадәр дәвам итә. Бу җиңүдән соң Советлар Союзының Бөек Ватан сугышында ьичшиксез өстенлек алуы ачыклана. Утлы дугада бүген тарихны өйрәнүчеләр күзлегеннән караганда да башка сыймаслык «тимер сугыш»ны кичерүчеләр арасында Кайбыч районының Иске Чәчкап авылы егете Зиннәтулла абый Заһидуллин да була.

Бик куркыныч булды

Быел август аенда Зиннәтулла абыйга, аз да түгел, күп тә түгел, 103 яшь тула. Бу якларга килеп чыксак, без аның янына сугылмый китмибез. Кайберәүләр, Зиннәтулла бабай турында бик еш язасыз, дип, дәгъва да белдергәли. Әмма моңа исебез китми. Беренчедән, гасыр кичкән, сугыш афәтен күргән ветеранның хәлен көн саен белешеп торсак та, артык булмас иде. Икенчедән, Курск дугасындагы хәлләрне үз күзләре белән күргән кеше буларак, без аның сөйләгәннәрен тагын бер кат тыңладык. Вакыты шундый бит. Һәр сүзе тарихта калсын, дидек.

Үтенечебезне җиткергәч тә, ул кинәт кенә сөйләп китә алмады әле. Бер ноктага карап, уйланып утырды. Аннан, ай-яй, ут эчендә яшәдек без анда, бик куркыныч булды, дип әйтеп куйды. Шуннан соң гына ачылып китте.

– Мин минометчы идем. 1943нең маенда безне Ржевка таба алып киттеләр. 20 көн җәяү бардык. Егерме беренче көнне, ниһаять, ял иттек. Кеше төсле йокладык. Шәп итеп ашаттылар. Икенче көнне сафка тезеп куйдылар. Каршыбызга бер офицер чыгып басты. 15 кешене сайлап алды. Мин дә шунда эләктем. Бергәләп фронт сызыгына таба юнәлдек. Караңгы төшкәндә кузгалабыз, иртәнге 7ләргә кадәр барабыз. Шулай итеп ике атнадан артык юлда булдык. Үзара: «Монда бик каты сугыш буласы икән. Немецлар, икенче Сталинград ясыйбыз, бөтен әйберне юкка чыгарабыз, дип әйтәләр икән», – дигән сүзләр ишетелә. Билгесезлек инде. Көтеп ятабыз шулай. Ишетелгәннәр рас килде. 5 июль көнне иртәнге сәгать 3тә беренче тапкыр бомба яудырып киттеләр. Карап торырга да куркыныч иде бу күренеш. Бер килгәндә 10ар, кайчагында 40ар самолет очып килә. Бөтен тирә-якны ут чолгап алды. Берни күренми. Кичке 7гә кадәр шулай булды.

7 июль көнне танклар ташкыны агылды. Безне күрмәсеннәр дип, маскировка ясап өлгергән идек. Яныбыздан гына үтеп киттеләр. Бик авыр булды ул. Нервлар соңгы чиккә кадәр киренкеләнде. Сулыш алуы да авыр. Тик, ничек булса да, түзәргә кирәк. Алар үтеп китү белән артларыннан ут ачтык. Бер танк та кире борыла алмады.

Танклар һөҗүменнән соң яхшы коралланган гаскәр җибәрделәр. Строй белән атлап киләләр болар. Бездән бер чакрым ераклыкта гына инде. Аермачык күренеп торалар. Бергә тупланыр өчен, безгә артка китәргә, чигенергә кушканнар икән. Каршы яктагылар киткән. Команда нишләптер безгә килеп ирешмәде. Инде немецлар килеп җитә язган иде. Без һаман минометтан атабыз. Шулвакыт: «Җыеныгыз, чигенәбез», – дигән команда ишетелде. Чак кына ычкындык. Ходайның рәхмәте, беребезгә дә зыян килмәде. Немецлар килә дә килә, берзаман элек безнең гаскәр торган урынны да каплап алдылар. Ә без, бергә тупланып, шул вакытта гына һөҗүмгә күтәрелдек. Түзә алмадылар, борылырга мәҗбүр булдылар.

Җиңү җиңел бирелмәде. 7 июльдән 23 августка кадәр 100 чакрым ара гына үтә алдык. Көненә 1–3 километр дигән сүз инде бу. Нинди хәлләр булганын шуннан да чамаларга була. Сугышның ничек барганын әйтеп, сөйләп кенә бирә торган түгел. Монда иң зур танк дивизияләре сугышы булды. Тирә-як ут эчендә калып, мартен мичләрендәге кебек корыч кайнап торды, җир өсте кан катыш тузан белән капланды. Каты сугышлардан соң совет гаскәрләре немецларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Харьковка ике километр кала туктадык. Шәһәрне җимерәселәре килмәде чөнки.

Немецлар атудан туктамадылар. Бик ачыклыкта ятам кебек тоелды да, бер окоптан икенчесенә сикерим дигәндә, сул яктан аркама һәм уң кулыма снаряд кыйпылчыгы килеп эләкте. Ут астында санбатка алып бара торган түгел. Уйсу җиргә урын әзерләделәр дә яралыларны шунда китереп салдылар. Санинструкторлар килеп, яраларны бәйләделәр. Бер көн яттык шулай, икенче көнне яңгыр ява башлады. Юешләнеп беттек. Кайберәүләргә рәхәт: йөри дә алалар, ә миңа, ике ягым да яралы булганга, кузгалмыйча чалкан ятарга туры килде. Шулай бервакыт, немецлар Харьковтан чыгып качкан, дигән хәбәр килеп иреште. «Котылдык», – дип, җиңел сулап куйдык. Ике көннән соң шәһәргә килеп эләктем. Ленин бакчасында 2–3 көн кундык. Нәрсә булгандыр, көннәрдән беркөнне иртә белән торганда, аякка баса алмадым. Энә белән чәнчиләр, берни сизмим. Тылга алып китәргә карар кылдылар…

Югалттылар

Шуннан соң Зиннәтулла абый тормышында икенче этап башлана.

– Вагонда тәрәзә буена эләктем. Температурам 40 градуска кадәр күтәрелде. Үтәли җилдән үпкәләрем шешкән булып чыкты. Харьковтан ерак түгел төшереп калдырдылар. Өч көн азаплангач, рәтләнә башладым. Ноябрь аенда тагын алып киттеләр. Төмән ягына бара торган поезд булып чыкты. Бик үтенеп сорагач, туган җиргә якынрак дип, Уфада төшереп калдырдылар. Бәхетемә, госпитальдә баш табиб Казанныкы булып чыкты. Дәвалый башлады бу мине. Бер ун көннән соң энә белән төртеп караса, аягым селкенеп китте. Ике шәфкать туташын билгеләде дә, алар мине баскыч буйлап йөрттеләр дә йөрттеләр. Бераз җайлангач, комиссиягә куеп, 6 айга өйгә кайтарып җибәрделәр. 1944 елның 25 гыйнварында поездда Колаңгы станциясенә кайтып төштем. Вакыты җиткәч, хәрби комиссариатка бардым. Хирург карады да: «Яраларың төзәлеп җитмәгән әле. Юлга чыгарып җибәреп булмый», – диде. «Болай да фронтка китәргә кешеләрем җитми», – дип военком бик ачуланды ачулануын, әмма табибка каршы килә алмады. «Үзебез чакыртырбыз. Өеңдә генә тор», – дип чыгарып җибәрде. Шулай яши торгач, сугыш та тәмамланды. Хәлләрне белешергә дип, комиссар янына барсам, зилзилә бураннары купты. «Син кая югалдың?» – дип эт итеп сүкте, кабинетыннан куалап чыгарды. Бер ярты сәгатьтән чыкты да гафу үтенде. «Документларың шкафта яткан икән, күрмәгәнбез», – ди…

Зиннәтулла абый, истәлекләренә бирелеп, матур гына тормыш итеп ята әле. Ике таякка таянып йөри үзе. Әмма ярдәм итим дип килсәң, шундук туктата. Үз көченә ышанырга өйрәнгән. Кунаклар да еш килә аның янына.

– Район башлыгына да, башка җитәкчеләргә дә рәхмәт яусын. Гел игътибар үзәгендә тоталар. Көн башландымы: «Зиннәтулла абый, берәр нәрсә кирәкмиме?» – дип шалтыратып торалар. Кирәкми бер әйбер дә. Ходай язган гомерне матур гына яшәп бетерергә дип кенә уйлыйм инде. Күршем Фәридә инде ничә еллар мине карый. Аңа рәхмәтләрне әйтеп бетерә торган түгел, – диде ул.

Зиннәтулла абый җор теллелеген бер дә җуймый. Фотога төшерергә дип, орден-медальләр тагылган пинжәген кидергәндә: «Ник, көн суындымыни? Әле генә җылы иде бит», – дип шаяртып куйды. «103 яшь тула бит. Кеше ышанмаслык», – дип уйланып алды да, «Нишлисең инде, безне бит, артка юл юк, туктарга да ярамый. Алга таба гына барырга, дип өйрәттеләр», – дип, кет-кет көлеп тә куйды. Күрәсең, истәлекләргә бирелеп, тагын бер кат Курск сугышын искә алуы иде аның.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

КУРСК СУГЫШЫНДА:

- Совет армиясендә югалтулар саны – **860** мең кеше. Шуларның **255** меңе хәбәрсез югалган.
- Курск сугышы барышында совет гаскәрләре **30** немец дивизиясен (шул исәптән **7** танк дивизиясе) юкка чыгара.
- Дошман **500** мең кешесен (үтерелгәннәр, яраланганнар, әсирлеккә төшкәннәр) югалта.
- Советлар Союзы Герое исеменә **180** солдат һәм офицер лаек булган. **100** мең кеше орден һәм медальләр белән бүләкләнгән.

КУРСК ДУГАСЫНДА – ТАТАРЛАР

«Хәрби Дан клубы» ассоциациясе җитәкчесе Михаил Черепанов биргән мәгълүматлар.

✓ Курск дугасында Татарстаннан хәрби хезмәткә алынган **10** меңгә якын кеше һәлак була. Клубның эшче төркеме әлегә шуларның **5500**ен генә ачыклый алды.

✓Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар арасында Татарстаннан ике кеше бар:

1. Салихов Гатаулла Салих улы, 1924 елда Арча районының Түбән Оры авылында туа.

2. Фомин Михаил Сергеевич, 1923 елда Менделеевск шәһәрендә туа. Шулай ук **Мифтахов Әмин Хәләп улы** (1923 елда Ютазы районы Еновка авылында туа) Герой исеменә тәкъдим ителә, әмма бүләк иясенә барып җитә алмый.

✓Курск сугышында күрсәткән батырлыклары өчен үлгәннән соң бүләкләнгән тагын **50**дән артык татарстанлының документлары табылды. Шуларның **17**се – татар милләтеннән.

✓Танклар бәрелеше нигездә дүрт өлкәгә кергән территориядә бара. Бүгенге Белгород өлкәсе һәм Белгород территориясендә – **2020**, Курск өлкәсе һәм Курскида – **1844**, Орел өлкәсе һәм Орелда **4582** татарстанлы һәлак була һәм төрле яралардан үлә. Харьков өлкәсендә Татарстаннан **3569** солдат һәм офицер җирләнгән дип исәпләнә.

ЙӨРӘККӘ СЫЙГАН БАРЫСЫ...

Язмыш кешеләрне сынарга ярата. Кайберәүләр аның ачысына түзми. Кайберәүләр исә язмышның якасына ябышып, күпләргә үрнәк булып яши. Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында яшәүче Надия Сәфәргалиева 22 ел буена авыру ирен тәрбияли. Җылы ояларына өч ятим баланы да сыендырган алар.

Үз балабыз булмады

Надия апа 19 яшендә кияүгә чыга. Фәргате белән бик матур яши башлыйлар. Бер-берен өзелеп сөйсәләр, аңлашып яшәсәләр дә, тормышларының китек ягы да була. Никадәр генә өмет итсәләр дә, Аллаһы Тәгалә аларга сабый бирми. Алларына утыртып, тупырдатып бәби сөясе килгән чаклары бик күп була Сәфәргалиевларның. Җитмәсә, моннан 22 ел ире юл фажигасенә очрый.

– Ул чакларда бик авыр иде инде. Үземдә яшәр көчне каян тапканмындыр – белмим. Әле бит күзләремә карап, җылы сүз көтүче Фәргать абыең да бар. Аңа да терәк булырга, күңелен күрергә кирәк. Икәү бергә булганда, сынауларны җиңәсен белдек без, – дип сөйли үткәннәрен Надия апа. – Ирем урынга яткач, ичмасам, балабыз да булмады дип, бик уфтандым. Фәргатькә дә өйдә ялгызына читен иде. Әгәр бала алсак... Менә шулай дигәнемне сизми дә калдым. Ирем каршы килмәде. Иртәгесен, тәвәккәлләп, район опека бүлегенә киттем. Нинди документлар җыярга кирәген аңлаттылар. Мәшәкате бик күп икән! Әмма артка юл юк. Алам булгач алам, дидем. Шунда бер танышым киңәш бирде: «Надия, син баланы барып күр дә кунакка алып кайт. Шулай эшләсәң, рәсмиләштерүе җиңел аны».

Надия апага шушы сүз җитә! Опека бүлегендә, бер кыз кирәк иде, дип әйтеп тә куя ул. Күп тә үтми, аны балалар күрсәтергә дип чакыралар. Сабыйларның йөрәген яраламас өчен, иң элек компьютер аша гына карыйсы, ошаса, яныңа алып чыгалар. Мәш килә Надия апа. Кат-кат карый-карый, үзенә кыз эзли. Озак сайлый. Шунда җитәкче ханым: «Кара әле, Надия, хәзер бер кызны алып керәм. Мин аны сөйләштерермен, ә син күзлә», – ди.

– Ишектә сабый күренүгә, йөрәгем дерт итте. Минеке бу, дидем эчемнән. Килеш-килбәте дә үзем инде. Кадрияне икенче көнне кунакка алып кайттык. Ул бездә яшәп калды. Барыбызны да яратты. Әтием-әнием дип кенә торды. Тик менә өч ел элек арабыз өзелде. Чит кеше сүзе үзенекен итте. Аннары геннары да үз эшен эшләде. Мин ялгышмасын, хаталанмасын дип тырыштым. Ә ул исә аңламады, бездән чыгып китте. Моны бик авыр кичердем. Еламаган көнем булмады. Йөрәгемнең чите кителде. Бар җылымны биреп үстергән балам иде бит ул, – ди Надия апа.

Икенче булып бу йортка Надия апаның бертуган апасының кызы кайта. Туганының баласын читләргә бирәсе килми аның. Кызчык та үз итә аларны, әтием, әнием дип эндәшә башлый. Инде Элинага да 21 яшь тула икән. Быел Казан медицина көллиятенең фармацевтика бүлеген тәмамлый. Әти-әнисенә бик рәхмәтле ул. Надия апа үзе дә кызы турында бик яратып сөйли, уңышларына сөенеп торабыз, ди.

Айрат бу йортка өченче бала булып кайта.

– Ятимнәр йортына бер малайны китергәннәр икән. Җитәкчесе, шалтыратып: «Надия, бездә бер малай бар, аның пөхтәлеге, бөтен бала урамнан пычракка батып керә, ә бу бала чиста йөри», – диде. Ул чакта Айратка 5 яшь иде. Килеп керүгә, бер генә күз ташладым. Бу бала нәкъ үзем иде. Ничек охшагандыр ул безгә – белмим. Күрүгә үк йөрәк урыннан кузгалды. Шулкадәр тәрбияле булып үсте ул. Кәефем булмаганны белсә, чәчәк гөлләмәсе күтәреп кайта, – дип сөйли Надия апа.

Рәхмәт кенә аз

Айрат әнә шулай ди. Ул үзен үстергән әти-әнисен хөрмәт итеп тора. Әтнә техникумында пешекчегә укып чыгып, үзмәшгуль булып теркәлгән. Ике ел инде Татарстан халкын тәмледәнтәмле ярымфабрикатлар белән сыйлый икән. Хезмәт сөюче гаиләдән эшкә уңган ул үсеп чыккан.

– Мин үз әти-әниемне хәтерләмим дә. Балачагымны Әтнәнең Олы Мәңгәр авылында башлаган тормышымнан хәтерлим. Димәк, алдагы еллар уемнан уелып төшеп калган инде алар. Бу йортка килеп кереп, мин бәхетнең үзен таптым. Ятим балага җылы кирәк икәнен һәркем белә. Ә бездә аның беткәне дә юк. Әтием белән әниемнең җылысы бар җиһанга җитәрлек. Алар безне җил-давыл тидермичә үстерде. Без дә аларга игелек күрсәтеп яшәтсәк иде, – ди Айрат.

Без килгәндә, егетнең мантый ясаган вакыты иде. Ун төрле ризык әзерләп сата икән. Әле аның янына әнисе әзерләгән каймак, сыр, куертылган сөт, корт, май да бар. Шулай ук казылык, сосиска, тутырма, колбасалар да ясап саталар икән.

– Миңа ярымфабрикатлар әзерләү бик ошый. Яратып эшлим. Кешеләр пилмәнне күп сорый. Ясап кына өлгер. Аны кайбер көнне өмә җыеп та әзерлибез. Көненә 25 килограмм пилмән бөккән чаклар да бар. Үз клиентларыбыз булгач, берсен дә кире борасы килми. Кеше канәгать калсын өчен, төннәрен дә йокламыйча эшләгәнебез бар. Әгәр без әзерләгән ризыкны яраталар икән, арулар да бетә, эшлисе генә килеп тора, – ди Айрат.

Фәргатем

Без килгәндә, Фәргать абый ятып кына тора иде. Катлаулы операция кичергән икән. Әлегә утырып торырга да ярамый. Алар бер-берен аңлап яшиләр. Күзләреннән шуны күрдек без. Аларда әле яшьлектәге ярату очкыннары да сүнмәгән. Авырлыклар тагын да ныграк якынайткан гына үзләрен. Фаҗигадән соң бөтенләй үз эченә бикләнеп, беркая да чыкмыйча яшәгән Фиргать абый үзенең йөри алмавы белән күптән килешкән.

– Өч ел буена урамга да чыкмады. Кеше күзенә күренергә читенсенде. Инвалид арбасына утыруны авыр кичерде. Хәзер инде бар да башкача. Язмышыбыз белән килештек. Димәк, без үтәсе сынау шушы булган. Мин үзем дә иремне аягына басар дип ахырга кадәр көттем. Табибларның «йөри алмаячак» дигән сүзе генә сискәндереп җибәрде. Әмма ул чакта да бирешмәдем. Язмышка үч итәсем, иремне терелтәсем килде. «Йөри алмаячак» дигән сүз мине тагын да ныграк көчле итте, – ди Надия апа. – Бүгенге тормышыма шөкер дип сөенәм. Улым, кызым бар. Фәргатем бар эшкә булышып тора. Тырышып яшәп ятабыз инде шулай. Ишегалды тулы кош-корт. Әзерләгән ризыкларыбызны мактап ашыйлар. Көннән-көн клиентларыбыз арта. Көч барда эшлисе иде әле. Шөкер, тырышлык бушка китмәде, балаларның киләчәген кайгыртып куйдык. Фатирлары да бар. Һәр ата-ана баласына нәрсә бирә – шуны булдырырга тырыштык. Ә иң мөһиме – яраттык без аларны. Чит итеп түгел, үзебезнеке итеп. Әле дә шулар дип өзгәләнеп торабыз. Ә гомер дигәнең выжлап кына узып бара. Әле ярый шушы балаларны үзебезгә алганбыз, димен. Тормышның яме, яшәүнең гаме – аларда бит!

ИЛФАТ ХӨСӘЕНОВ:

«Яңадан җыйдылар»

Көчле рухлылар

Арча районының Наратлык авылында гомер итүче 58 яшьлек Илфат Хөсәенов турында күп еллар элек бер язган идек инде. Тагын хәлләрен сораштык.

– 2012 елда хатынымны югалттым. Миләүшәмә 42 яшь иде. 22 ел яшәп калдык. Өч балам – әнисез, үзем тол калдым. Җиңел булмады. Сабыйларым хакына яшәү көчен таптым. Ничек тә кешедән ким-хур булмаска дип яшәргә тырыштык, – ди Илфат абый.

Хатыны үлгәч, дүрт елдан юл һәлакәтенә очрый ул. Арчадан авылына кайтып килгәндә, машинасы юл кырыена төшеп китә. Кече улының мәктәптән кайтуына җылы ризык әзерлим дип, кызурак та барган була. Ашыгу үзенекен итә. Илфат абыйның машинасы җиде тапкыр әйләнә. Әле ярый үзе, бәрелүгә үк, машинасыннан төшеп кала. Тик барыбер имгәнүе гомерлеккә була. Умырткалыгына зыян килә, кабыргалары сына.

– Бик озак хастаханәдә яттым. Аннан кайткач та күп тернәкләндерү курслары үттем. Әле дә йөреп торам. Ике елга бер тапкыр Яшел Үзәндә урнашкан үзәккә барып дәваланам. Аякка басасы килә бит. Миңа тик тормаска кирәк. Кая барып була, шунда чыгып китәм. Ялы түгел, инструктор белән шөгыльләнүе кирәк аның миңа. Анда баргач, бер генә минутны да әрәм итмим. Алайса, күп кеше килә дә урында ята. Тернәкләнеп түгел, киресенчә хәлсезләнеп кайталар, – ди Илфат абый. – Бар да үзеңнән тора. Үҗәтлегем, тормышка ябышуымны күрүчеләр дә бар. Алар мине үзләренең авыру якыннарына үрнәк итеп куялар. Башкалар, миңа карап, үзләрендә яшәр көч табалар икән, мин моңа шат кына. Үземдә уңай якка үзгәреш сизгәч, гел шөгыльләнәсе генә килеп тора. Әкренләп аякта басып торырга өйрәндем. Тотынып йөри торган җайланмам бар. Аякларны гел хәрәкәттә тотарга кирәк. Тренажерларымда күнегүләр ясыйм.

Ул әлеге хыял белән 7 елга якын яши. Баштарак кеше ярдәменнән башка берни эшли алмаса, хәзер инде тернәкләндерү үзәкләренә дә үзе генә йөри. Коляскасына утырырга да, аннан төшәргә дә өйрәнгән. Ашарга да үзе пешерә, өен дә чиста тота.

Кызы Илзирә гаиләсе белән Йошкар-Олада яши. Уллары Илназ белән Инзил әтиләре янында.

– Күңел төшереп утырудан ни файда? Ялкау булмаска, үзеңә тырышырга кирәк. Инвалид арбасына калгач, шуны аңладым: һәр кеше үз сәламәтлеген кайгыртып яшәсә генә, алга китеш була. Чир сине түгел, мин чирне җиңәм, дип яшәргә кирәк. Әгәр тормышның якасына ябышмаган булсам, мин урыннан да тормаган булыр идем, – ди Илфат Хөсәенов. – Балаларым хакына яшәдем дә инде. Ә хәзер оныкларым сөендерә. Миңа берничек тә төшенкелеккә бирелергә ярамый. Алга гына барасы. Әлегә арба белән. Әмма озакламый үз аягым белән дә йөрермен дип уйлыйм.

Гөлгенә ШИһАПОВА

КӨРӘШЧЕ РАДИК СӘЛАХОВ:

«ТУГАН АВЫЛДАГЫ КЕЛӘМ КАДЕРЛЕРӘК»



«Көрәш чир кебек ул», – ди Зәй егете Радик Сәлахов. Быелгы Федераль һәм Халыкара шахтерлар Сабан туенда, Киров өлкәсендә батыр калган егетнең откан машиналарын да, титулларын да санадык. Ни өчен яшьләр көрәшкә битараф? Оттырганнан соң келәмгә чыгу авырмы?

Сармашбаш егетләре

:: Мәрхүм әтиегез Сирин – байтак кына батырларны әзерләгән тренер. Сезне дә көрәшкә ул алып килдеме?

– Әйе. Миңа ул чакта алты яшь иде. Бер көрәшеп карагач, келәмнән чыгасы килмәде. Әти заманында үзе дә көрәшкән. Аннан соң, безнең авылны (Зәй районының Сармашбаш авылы. – **Авт.**) электән көрәшчеләр авылы дип йөртәләр. Сармашбаш егетләре көрәшсез яши алмыйдыр ул. Һәрхәлдә, без үскәндә, башка малайларга кызыгып булса да көрәшә башлаучылар бар иде. Көрәш чир кебек бит ул. Туктап булмый. Шөкер, җиңүләрем дә җитәрлек. Әмма яулыйсы үрләр дә бар әле.

:: Җиңүләр, димәктән, иң әһәмиятлеләрен барлыйк әле.

– Дүрт тапкыр Муса Җәлил турнирында, ике тапкыр дөнья чемпионатында, өч тапкыр Россия һәм биш тапкыр Татарстан чемпионатларында җиңдем. Дөнья чемпионатында тагын берәр мәртәбә җиңәргә иде әле. Тагын бер зур максатым – Россиянең атказанган спорт остасы исеменә лаек булу.

:: Титулларның күп булуы көрәшергә ярдәм итәме?

– Ничек дип әйтергә икән? Аның җаваплылыгы күп. Әйтик, дөнья чемпионатын откан көрәшчедән, кая барса да, җиңү көтәләр. Урамнан кергән малайга җиңелеп булмый. Көчле булуыңны исбатлап торырга кирәк.

:: Җиңелүләрсез дә булмый бит. Алары истә каламы? Бер җиңелгәч, яңадан келәмгә чыгу авыр бирелә ме?

– Оттыру бик авыр, билгеле. Андый чакта, бүген – ул, иртәгә мин аны җиңәм, дип фикер йөртергә, шуңа ышанырга кирәк. Һәм, әлбәттә, хаталар өстендә эшләргә, шөгыльләнергә, шөгыльләнергә һәм тагын бер кат шөгыльләнергә.

Радикның әтисе һәм беренче тренеры Сирин Сәлахов сөйләгәннәрдән:

> Шулай бер елны Питрәч районына ярышларга барган идек. Ул чакта Радик IV урында калды. Ярышлар Сабан туе уза торган урында – урман янында узды. Менә шул урманны чыкканчы икәүләшеп еладык... Радик кечкенә иде ул чакта. Өстәвенә тәүге ярышлары. Тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: җиңелгәннән соң елый икән, көрәшчедән ни дә булса көтәргә була әле. Ә инде җиңелгәннән соң уйнап-көлеп йөрсә, аның белән шөгыльләнүдән файда юк.

Кыйммәтле келәм

:: Радик, быел Киров өлкәсе Сабан туенда унынчы машинагызны оттыгыз. Бәлки, быелга соңгысы да булмас әле. Ул машиналарны нәрсә эшләтеп бетерәсез?

– Күп очракта сатып җибәрәбез. Саклап ятып булмый бит. Кайчакта үзем дә йөрим инде.

:: Шулай да, көрәш – шөгыль генә дер?

– Әйе, тормышны алып барырга кирәк бит. Хәзерге вакытта Чаллыда торба заводында эшлим. Ләкин атнасына ким дигәндә өч тапкыр тренировкага барырга вакыт табам.

:: Матур гына Әлмәт өчен көрәшеп йөргән җирегездән Лаеш командасына күчтегез. Гомумән, көчле «легионерлар» күп ул командада. Сер булмаса, ничек итеп җәлеп итәләр сезне?

– Шәхсән миңа алар тәкъдим иткән шартлар ошады, баш тарта алмадым. Ә гомумән алганда, Лаешта, башка районнар белән чагыштырганда, җитәкчелек тарафыннан татар көрәшенә зур игътибар бирелә. Бу – бер мөһим ягы булса, матди як – икенчесе.

:: Сезнең өчен нәрсә мөһимрәк: туган авылыгыздагы Сабан туенда баш батыр калумы, федераль дәрәҗәдәге бәйрәмдәме?

– Туган авылда баш батыр калу күңеллерәк тә, мөһимрәк тә. Дусларың, туганнарыңның җан атуын, горурлануын күрү – үзе бер рәхәт. Ләкин федераль Сабан туенда батыр калган юк иде әле, анысына да бик шатмын.

:: Соңгы елларда көчле көрәшчеләр рәтендә һаман бер үк егетләр йөри, яңа исемнәр бик күренми. Яшьләр татар көрәшенә нигә битараф икән?

– Татар көрәшенә җитәкчелек тарафыннан игътибар да җитәрлек бирелә, яшьләрнең аз булуы чыннан да борчый. Ә бит өметле, көчле егетләр шактый. Зурлар арасына керә алмыйлар да көрәшне бөтенләй ташлыйлар. Йә булмаса, районнарында игътибар җитми. Аннан соң, хәзер егетләрне башкачарак тәрбияләүләр кебек. Ул да йогынты ясамый калмый. Заманасы шундый: патриот кына булып булмый, бөтен нәрсә акчага бәйләнгән. Яшь көрәшчеләрне дә ярышларның приз фондларын арттырып җәлеп итеп була.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Күңелле, мәгънәле, безнеңчә

Сабан туе һәм, гомумән, милли бәйрәмнәр үзгәртеп кору чорын кичерә. Күңел ачу янында мәгънәсе дә булсын дип бурыч куйдылар быел. Түбәтәй һәм калфак киючеләр артты, ә бәйрәмне үзгәртә алдыкмы?

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, быелгы Сабан туйларында, кайда узуына карамастан, эчтәлек, онытыла язган традицияләр алгы планда булырга тиеш иде. Бер ерагайгач, тамырларга кире кайту алай тиз генә башкарыла торган эш түгел, билгеле. Шулай да, багланган өметләр аклана башладымы соң?

Иң көтелгән һәм иң зур игътибар бирелгән Казан Сабан туеннан башлыйк. Тынычлык бистәсендә узган бәйрәмне ачканда Рөстәм Миңнеханов болай диде: «Безгә бу бәйрәмдә милли мәдәниятебезнең тарих сәхифәләренә мөрәҗәгать итү җитми иде. Ә бүгенге бәйрәмне оештыручыларга бик зур рәхмәт! Киләчәктә дә шушындый бай тарихыбызны, гореф-гадәтләребезне саклап, бәйрәмнәрдә күрсәтербез дип ышанам». Ягъни беренче адым ясалды.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин сүзләренә караганда, бу үзгәрешләрне төп бәяләүче – халык та сизгән. Районнар корган ишегалларында, һәрвакыт ук булмаса да, тере музыка тавышы ишетелеп торуына, остаханәләрнең татарларга хас булган кул эшләре, һөнәрчелекләргә багышлануына, һәркемгә милли ризыкларыбызны пешереп карау мөмкинлеге бирелүенә «ВТ» хәбәрчесе дә игътибар иткән иде. Иң мөһиме – болар барысы да концерт карап туйган халыкка да кызык булды. Аерым алганда, ишегалларының берсе дә буш тормады.

– Быелгы барлык бәйрәмнәр дә эчтәлеге белән аерылып тора. Аларның асылына, мәгънәсенә, традицияләргә зуррак игътибар бирергә һәм шуларны мөмкин кадәр киңрәк аудиториягә җиткерергә тырыштык. Әлегә без юлның башында гына – башкарасы эшләр күп, – диде Дамир Натфуллин журналистлар белән очрашуда, узарга өлгергән бәйрәмнәргә кыскача гына йомгак ясап.

Киләсе елга тагын да тырышачакбыз, диде ул. Милли гореф-гадәтләр бу хакта берни белмәгән бала-чага һәм яшьләргә дә кызык булсын өчен күп эшләргә туры киләчәк әле.

2023 ЕЛГЫ САБАН ТУЕ – САННАРДА

✓ быел Россиянең **61** төбәгендә һәм **36** илдә барлыгы **294** Сабан туе узарга тиеш, **175**е инде узган;
✓ Казан Сабан туенда **170** меңләп кеше катнашкан. Сабан туе кунаклары **20** меңләп өчпочмак, **10** меңләп пәрәмәч, өлеш кебек башка камыр ризыклары ашаган һәм **3** мең литр чәй эчкән;
✓ чит төбәкләр арасында иң күп кеше Мәскәү Сабан туена килгән. Оештыручылар, **250** мең кеше җыелды, ди.

Милли кием

Быелгы Сабан туенда игътибар үзәгендә булган тагын бер мәсьәлә – милли кием. Алдан ук үзебезнең бәйрәмгә үзебезчә киенеп килергә киңәш ителгән иде. Төгәл генә санамасалар да, Тынычлык бистәсендәге бәйрәмгә килгән халыкның якынча 20 проценты милли киемнән иде, дигән нәтиҗә чыгарганнар. Шунысы кызык: Дамир Натфуллин сүзләренә караганда, башка төбәкләрдә узган Сабан туйларына милли киемнән килүчеләр бермә-бер күбрәк.

Казан Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов фикеренчә, кешене бәйрәмгә милли киемнән килергә мәҗбүр итеп булмый. Һәркем үзенә уңайлыны сайлый. Шулай да, ниндидер этәргеч бирергә була. Гади генә мисал: быелгы Казан Сабан туенда милли киемнән килүчеләрне фотога төшерделәр. Озын булмаса да, оста фотографлар янында калфак-түбәтәй кигән кешеләрдән үзенә күрә чират та җыелган иде.

Әмма бу очракта милли кием индустриясен тулаем кararга кирәктер. Әлеге дә баягы, бәя мәсьәләсе бар бит. Мәдәният министрлыгы бу өлкәдә нәрсәләр эшли? Милли кием индустриясен ничек тә булса контрольдә тотамы? Бу сорауны министр урынбасарына бирдек.

– Бәя мәсьәләсе, чыннан да, бик мөһим. Баштанаяк милли стильдә киенәсе булсаң, ул шактый кыйммәткә төшә. Ниндидер элемент кына аз кебек. Безнең төп максатыбыз – бу өлкәдә ниндидер алтын урталыкны табу. Быел бу юнәлешкә караган планнарыбыз күп. Аерым алганда, милли кием җитештерүчеләргә каралган грантлар системасын ныгыту, милли киемнәрнең, элементларның бәясен киметү буенча эш алып барыла. Нәтиҗәләрне ел ахырында ясарбыз, – дигән җавап белән чикләнде Дамир Натфуллин.

Ахыры. Башы 30 июнь санында >

Өйгә ямь тулды! Нур иңде! Тәрәзә төбендә чәчәк атмый утырган яран гөл бөреләрен ачты. Дамирның да җыерчыклары язылa төште. Үзгәрде әтисе, бик нык үзгәрде. Сабан туенда гына кигән шакмаклы зәңгәр күлмәген алып киде.

Зиннурга бу да ошамады:

– Бүген бәйрәм түгел лә! – дип борынын җыерды ул, бәлеш исен тоеп.

– Бәйрәм, улым! Нинди генә бәйрәм әле! Алсуыбыз терелде бит!

...Шул кичтә әтисе малайга бик куркыныч сүзләрне җиткерде:

– Улым! Син ничек уйлыйсың? Сания апаң бездә... тагын... беразга калсынмы?

Малай дерт итте. Башы гүләде, күзе томаланды, колаклары шаулады.

«Юк! Юк! Мең тапкыр юк!»

Бөтен күңеле, җаны шулай дип дулады малайның.

...Төнне ул тагын печәнлектә уздырды...

Иртән торып чыкса – шаккатты: сыер инде әллә кайчан көтүгә киткән... Кояш та әллә кая кадәр күтәрелгән... Әтисе дә инде күптән кырда...

– Ашыйсың килеп беткәндер, улым, әйдә, утыр...

дый чакта гел уйлап куя иде Зиннур: «Бераз үскәч, минем дә буем җитә башлар ул шүрлеккә!» – дип...

«Колга!» – дип кабатлады Зиннур, үртәлеп.

«Колга» чәй ясады, өстәлне ризык белән тутырды.

«Гөбәдия пешергән! Әтигә яраргa тырыша!»

Алар, сөйләшә-сөйләшә, чәй эчте. Зиннур тагын шуны аңлады: Сания беркая да китәргә җыенмый, бүген дә аларда кала икән...

* * *

Сания белән Зиннур, икесе ике тәрәзәдән карап, әтисен озатып калды. Әнә ул ераклашты, тыкрыктан борылып, күздән үк югалды... Бераздан Алсу да мендәргә чумып тынып калды... Малай шуңа игътибар итте: Сания каядыр җыена бугай. Алсуның йокларга ятуын, әтисенең өйдән чыгып китүен генә көткән, дияр сең. Матур күлмәген киде, башына ак яулык япты, аягына да яңа туфлиен элде.

– Минем барып кайтасы җирем бар иде... Бер-ике сәгатькә...

«Бар соң! Кит! Бөтенләй кайтмасаң да ярый!»

Боларның барысын да эченнән генә әйтте малай.

Хатын киткәч кенә, кабергә якын килде малай. Ике кабердә дә бер фамилия... Сабитовлар... Кырык яшьлек ир һәм уникe яшьлек малай... Ата белән ул! Икесе дә бер үк көндә... Кинәт Зиннурның күкрәгән нәрсәдер умырып алды да йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Сания апасының фамилиясе дә Сабитова бит! Сабитова Сания! Монда аның ире белән улы ята булып чыга түгелме соң? Узган җәйдә матайда капланып үлгән ата белән малай турындагы шомлы хәбәр хәтерне яңартты... Зиннур яшендәге малай... Айдар исемле...

Сания инде авыл читендәге өйнең ишегалдына кереп бара иде. Җыйнак кына калай түбәле йорт. Бакчасында алмагачлар үсеп утыра. Зиннур да аннан калмады, койма буена чүгәләп күзәтүен дәвам итте.

«Мөгаен, Сания апаның өедер бу!»

Шунда ишегалдында тагын бер хатын пәйда булды.

– Сания! Сания дим! Әллә синме соң?

– Мин идем... Я, хәлләр ничек? – дип елмайды Сания.

– Ничек булсын? Аллага шөкер! Син үзең бөтенләйгә кайттың штоли?

– Юк әле... Бөтенләйгә түгел... Әлегә аңа мин кирәк!

– Ярар, ярар! Изге эш эшлисең. Син йортың өчен борчылма, мин монда күз-колак булырмын.

– Рәхмәт инде, Фәния!

– И-и-иии... Рәхмәт дип инде... Күрше хакы – Тәңре хакы, диләр бит! Карале, шуны сорармын дигән идем: ул кешенең малае да бар дип ишеткән идем. Бик тәртипсез нәрсә түгелме? Борчып, җаныңа тимиме?

Зиннур калтырап куйды, җыерылып, койма буендагы куак төбенә сеңде.

– Юк ла, Фәния! Нишләп тәртипсез булсын, ди! Бик әйбәт, эшчән малай! Минем Айдарыма охшаган...

Аннан Сания, ашыга-ашыга, ишеккә йозак элде.

– Фәния, гаеп итмә, яме! Мин йөгерәм, малай! Алсуны йоклатып кына киткән идем. Ашыгам!

Сания авылга чапты. Очты гына...

...Ә Зиннур акрын гына атлады да атлады... Әллә ничек бик читен, уңайсыз иде аңа. Җан түрендә ниндидер килбәтсез зур, иләмсез авыр бер таш ята сымак. Әллә шуның күкрәкне кысуы, күңелдәге эчкерсез миһербанлыкны кысрыклавымы? Шул шыксызлык әллә бөтен күзәнәкләргә таралып, аякларга да уралып, аларны тышауларга өлгергәнме? Арынасы иде шуннан! Сафланып, җиңеләеп каласы... Һәм... Һәм кемнәндер гафу үтенәсе килә иде аның!

Малай елап җибәрде... Яшел чирәмдә ауный-ауный, тәгәри-тәгәри үкседе ул. Өстендәге ак күлмәкнең кызгылт таплар белән чуарланып, алсулана баруын да сизмәде хәтта...

Бераздан Зиннур, тынычланып, җиңеләеп калды кебек... Шунда гына күлмәгенә күзе төшеп, «ах!» итте. Җиләклектә утыра икән лә! Әнә бит, аунап, күпме җиләкне сыткан! Әрәм иткән дисә... Юк ла икән! Монда алар бихисап! Малай иң эре җиләкләрнең берсен алып авызына капты. Тагын, тагын өзде... Җиләк тәме бөтен тәнгә таралды, җанга сеңде. Очасы, канатларын җилпи-җилпи, әллә кая биеккә, болытларга кадәр күтәреләсе килеп китте аның!

– О-хо-хо-хоооо!

* * *

...Өйгә ул соң гына кайтты.

– Абыем! – дип, йөгереп, каршысына чыккан Алсуга бер кепка кып-кызыл җиләк тоттырды. Бер түбәләмә кепка җиләк!

– Мин үзем туйганчы ашадым. Монысы сезгә... Сиңа, әтигә... Сания апага...

Йөзенә моңсулык иңгән Сания елмаеп җибәрде...

ГҮЗӘЛ ӘДһӘМ

ҖИЛӘК ТӘМЕ

(ХИКӘЯ)

Өстәлдә тәлинкә белән катык тора. Кызыл төстәге чөгендер катыгы... Нәкъ шушындый итеп оета иде әнисе катыкны... Куе итеп... Кашык белән китеп-китеп ашарга ярата иде Зиннур аны...

«Юк! Ашыйсым килми минем! «Улым» димә миңа!»

Зиннурның әнә шулай дип кычкырасы килеп китте. Бәлки кычкырган да булыр иде... Тик шулчак алгы бүлмәдән Алсу атылып чыкты да малайның ике ботын чытырдатып кочаклап та алды:

– Абыем! Мин сине шундый яратам!

Үзе шундый кечкенә, маңгае да малайның кендек турына җитәр-җитмәс... Башын кыегайта төште дә, бер күзен кысып, абыйсына төбәлде:

– Мин сине яратам, абыем...

Үзенең күзләре ялтырый, ә борын яфрагындагы теге игезәк миңнәре дерелдәп-дерелдәп куя...

Зиннур кызчыкны кочаклады да борын очыннан үбеп алды...

Әллә ничә көннәр җыелып килгән ачуы да каядыр таралды, сибелде сымак...

* * *

Әмма теге сорау һаман тынгылык бирми, үрти, җанны тырнап чәбәләнә:

«Сания апаң бездә тагын беразга калсынмы?»

Бу турыда уйлыйсы килми иде Зиннурның. Синең уйлыйсы килү-килмәвеңнән генә мәсьәлә хәл ителсә икән ул! Әбәткә кайткан Дамир, улыннан җавап көткәндәй, сынап-сынап аңа карап куйды. Әмма малайның күзләре идәндә...

«Нишләргә? Ни дияргә? Барыбер җавап бирергә кирәк бит! Ул бит – әти! Әти сүзен җавапсыз калдырырга ярыймыни?»

Тагын бер нәрсәгә игътибар итте малай: әтисе, үрелеп, Санигә өске шүрлектән һинд чәен алып бирде. Әнисенә биргәндәй итеп! Буе җитә лә ул хатынның шүрлеккә! Ник җитмәсен – «колга» бит ул! «Кол-га!» Ә менә әнисенең шүрлеккә буе җитми иде. Кирәге чыкканда: «Дами-и-ир, алып бирче-е-е», – дип, әтисенә дәшәр иде... Ягымлы итеп, сузып әйтә иде ул әтисе исемен... Дами-и-ир... Шун-

Сания китте. Үзе артында әллә никадәр сорау калдырып китте. Малайда шик уянды:

«Кая китте ул? Барасы җирем бар дип, әтисенә дә берни әйтмәде».

Зиннурның хатынны ниндидер бер гөнаһлы эштә тотып, фаш итәсе килеп китте.

«Әшәке, җүнсез хатын булсын иде ул! Шул чакта әтисе соравына җавап бирү дә җиңел булыр иде. «Кирәге юк аның безгә, әти, өенә кайтып китсен!» – дияр иде.

Алсу әле барыбер тиз генә уянырга җыенмый, малай Сания артыннан чапты.

«Кая китте шулай Сания кача-поса гына?»

Хатын авылдан чыгып килә иде инде. Күрше авыл белән ике арада утыртылган каен посадкасы буйлап барды да барды ул. Каядыр бик ашыкты, ахрысы, артына да борылып карамады. Элдертте генә! Каен кәүсәләренә ышыклана-ышыклана, үзен күзәтеп килүче Зиннур барлыгын башына да китермәде, ахры.

Ике авыл арасы әллә ни ерак та түгел, күп булса, бер чакрым чамасыдыр. Посадка бетүгә, аңа күрше авылның зираты кушылып китә. Әнә шул зиратка барып керде Сания. Керде дә койма буендагы яңәшә кабер янында тукталып калды...

Малай әсәренде. «Кемнәр кабере икән ул? Өстен әле чирәм дә каплап өлгермәгән». Хатын чүгәләде... Куллары белән туфракка орынды... Әллә шулай итеп сыйпавы, иркәләве инде? Шулчакта хәтер түрендәге бер җәүһәр чәлпәрәмә килде. «Кем соң әле? Күңелгә бик якын берәү нәкъ шул ишарәне ясаган иде? Зиннур дерт итте: «Әтисе кебек! Әйе, әйе! Әтисе дә бит нәкъ шулай сыпырган иде туфракны... Әнисенең кабер туфрагын»...

Менә хатын кабер читендәге үләннәрне өзгәли башлады, үзе үлән йолкый, үзе бертуктаусыз нидер сөйләнә. Аралар шактый булганга, сүзләре Зиннурга килеп ирешми аның. Тукта, тукта! Сания апасы елый түгелме соң? Әйе, әйе! Елый бит! Әнә кесәсеннән кулъяулыгын да чыгарды...

Шигърият

Әхәт ГАФФАР

АЛ ҮЗЕҢӘ, ТУКАЙ!

Бу Ватанда яшәп киткәннәрнең
үлгәне юк әле кайгысыз.
Түргә омтылып та гүргә керми
калганыгыз бармы кайсыгыз?

Мин әйтмәдеммени бу дөньяның
тузыбыздан сут агызганын,
тормыш мунчасының ләүкәсендә
яфракларсыз сап «тамызганын»?

Түзә арка, түзә күкрәк, аяк
шәфкатьсезлек каезлавына.
Күпме түзик җанны шакшы җаннар
гомер бакый явызлавына?

Телдә Хәдис, уйда Алла ласа,
без Иблисләр түгел ләбаса!
Ни хәл итик: кабер ташларыбыз
үлмәс борын иманны баса.

Тимер гасыр каннан тоз агыза, –
каклаган каз кебек кибәбез.
Гасырларын көрнәп тегәр идек, –
күгәрек шул инде энәбез...

Ник туганга үкенерлек тә бит,
шулай да без – Сөю орлыгы.
Кая төшеп уҗым булырга соң? –
без иңәсе туфрак корыган.

Күз-колак та, аң да, җан да – күмер,
аяк атлыйм дигән җир – түмәр.
Очыйм дигән гәүдә сазга түнәр, –
кайсы йолдыз ләхетләп күмәр?

Суалчаны, кырмыскасы... барча
җан иясе терек иткәндә,
без – дәрвишләр:
һичнинди гөнаһсыз
советларда сөрген киткәннәр.
Җанның болгауларын тыңламагыз, –
шуннан башка юктыр тавыш-тын...
...Әллә кая – киләчәккә китеп,
ашыктың син, Тукай,
ашыктың!

Бүген:
«Китик!» – дияр идең бәлки,
әйдәр идең рухны очмакка...
Әллә кая китеп булмас инде:
ал үзеңә, Тукай, – ожмахка.

ИЛ

Тупыллар да яфрак ярды инде,
әти-әни кабере – канәфер.
Киттем әле, нурсыз Казан, сиңнән:
юк Туган тел, тулган тел кяфер.
Армышлар-талмышлар! Ялантәпи
ипи китерегез бер телем!
Кыерчыксыз учта үксеп елый
әти-әни КАБЕРЕДӘЙ ИЛЕМ...

ӘЛЛӘ ТАГЫН

Әй бу гомерләр!
Бер дога кылыйк,
йә бер көликме,
йә бер елаек?
Язгы ташкындай
азмы ашкындык, –
хәтердән җуймыйк шушы еллыкны.
Әллә сулыйкмы,
әллә яшәрик?
Умырзая да
яшәрә,
сула.
Кар сулары да төшә чәчерәп, –
яшәү мәңгелек,
югалмас череп.

ӘЙДӘ, ТАНЫШАБЫЗ

– Синең белән кайчан егет белән кыз сыман очраша башлыйбыз инде?
– Миңа 18 тулгач.
– Ә хәзер күпме соң сиңа?
– 28.

❤❤

– Ни өчен миңа үземнән күпкә яшьрәк егетләр тартыла икән?
– Чөнки балалар яхшы кешене күңелләре белән сизә.

❤❤

– Сез – шундый матур пар! Кайчан өйләнештегез?
– Мин – өч ел элек, ә ул – биш.

❤❤

– Кызлар, ышанасызмы, егетем белән ярты ел очрашып йөргәннән соң ул миннән: «Ә нигә синең һаман егетең юк?» – дип сорап куйды.

❤❤

– Йөргән кызым миңа «24» саны язылган футболка бүләк иткән иде. Юлларыбыз аерылды. Күптән түгел аны бер егет белән күрдем. Егетнең футболкасында «25» дип язылган!

Әз-мәз мәзәк

Мин җәйге ялга кадәр:
– Үз эшемне күралмыйм!
Мин җәйге ялдан чыккач:
– Үз эшеңне күрә алмау шулкадәр рәхәт икән!

* * *

Юлда бары тик бер нормаль шофер бар: син.

* * *

– Җәйге эсседән һәм черкидән кайларга гына качарга икән?
– Офиска.

Илсөя һәм Илфак улы | Казанда ресторан | Вәсим Әхмәтшин хиты | Мөслим Магомаев тавышы
Мәйдан берәмлеге | «Рио» һәм «Соул» | Нурлат районы авылы
Анда төштем, май ашадым | ... «Новости» | Пәйгамбәр
Ураза иртәнге ашы | «Әҗәл» Равил | Йошкар-...
Р.Мөхәммәдиев күпере | Винарис Ильегет | Абхазия курорты | Күкрәк «тавы»
Актриса ... Роговцева | «Синсез үткән гомерләрем булса ..., булмаса ...» | Авылда түбән һәм югары | «... барс» – чемпион!
Совет телевизоры | Сәхнә әһеле | Винни-Пухның ишәк дусты | ... Атнабаев | Рамил Юныс әтисе
Рус кенәзе | Оста укчы | Аспирин | ...-тирә дөнья
Раил Садриев кафесы | Боксчы Мөхәммәт | Х.Насретдин транспорты | Тәм туганы | Украина башкаласы | Егет булсаң, ... бул, суда йөзгән сөлек бул | Матурлык | Композитор Гатауллин | Казахстанда елга
Саннар дәлиле | Аның үрдәге сер тотмый | Бөек Ватан сугышы турында «... миллион» җыры | Тыныш билгесе | Киплинг ярымбүресе
Татар халык җыры | «Ай-..., замана»
Нур-Солтан булып алды | Краснодар крае экс-губернаторы | Туйдым!!! | ... Фәйзуллин | Ат апа
...-мим!
Теленә ... чыккыры! | Әзмәвер чөя
Рус әкиятләре герое | ...-Манш | «Итил суы ... торур» | Интеллигент
Татарстанда елга | Гыйлем – аның ялтысы

Сканворд җаваплары

Горизонталь: баритон, ар, Зирекле, РИА, сәхәр, Харун, Ола, Юанша, имчәк, Рекорд, Әнгам, Иа, Упса, Тамак, мәргән, әйләнә, статистика, Алиш, җәя, Риф, Әнисә, Егерме, ли, Ткачев, бия, ләм, гер, ака, зыялы, акыл.

Вертикаль: Сират, Астана, Хәким, Али, артист, Рюрик, ишәк, баз, Ада, ис, Алмаз, Нариман, тилчә, Ык, Шәрәфи, Емеля, Тимерхан, Киев, Ла, Киа, Гагра, гарык, Кошларга, җелек, Мөнәвәр, Равил, ни, ямь, Маугли, оч, Ләйсән, Или, Ак, Әлфия.

Беләсең килсә...

1 Бәрәңгене Россиягә беренче булып кем алып кайткан?
а) Петр I;
б) Екатерина II;
в) Александр I.

2 АКШ әләмендә ничә кызыл һәм ак сызык бар?
а) 13;
б) 15;
в) 17.

3 Нәкый Исәнбәтнең шушы исемдә пьесасы бар:
а) «Дипломат»;
б) «Чемодан»;
в) «Портфель».

4 Бер дюймда ничә сантиметр?
а) 1,95;
б) 2,38;
в) 2,54.

Җаваплар: 1. а); 2. а); 3. в); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 295

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+